# Түгәрәк уен

ХАЛЫК ИҖАТЫН ЯКТЫРТУЧЫ МӘГЪЛҮМАТИ-ПОПУЛЯР АЛЬМАНАХ

4/ 2024

*Татар кызы икәнлеген күрсәтеп тора торган нәни калфакчык, яки нәни изү элементы XX гасыр башында үзгәрә башлый. Хәзер модельер-дизайнерлар әлеге элементларны бүгенге көнгә яраклаштырырга һәм киләчәккә алып барырга тырыша*







Рәмилә Сәләмова фоторәсемнәре

# «ИҢ КҮП КАЗЛАР – МӨСЛИМ РАЙОНЫНДА»

**Күптән түгел Мөслимдә «Каурый төшә карларга» дип аталган IV Бөтенроссия «Каз өмәсе» фестивале үтте. «Финалның инде дүртенче ел Мөслимдә узуы очраклы түгел. Мөслим ягының заманча каз үрчетү оешмалары ил күләмендә дан тота, каклаган казы бөтен Россия буенча танылган.**

Татарстанда иң күп казларны Мөслим районында асрыйлар», – диде бәйрәмгә кунак булып килгән «Ак калфак» татар хатын-кызлары республика иҗтимагый оешмасы җитәкчесе Кадрия Идрисова.

Бәйрәм «Яшьлек» спорт комплексында театральләштерелгән тамаша белән башланды. Биредә төрле мастер-класслар күрсәтелде. Апалар-кызлар каз йолкыды, каурый сыдырды.

Мәлләтамак авыл җирлеге килен төшерү йоласын күрсәтте. Мөслим сәнгать мәктәбе хезмәткәрләре төрле тукымаларга каз сурәтләре төшерде, Туган як музее хезмәткәрләре милли үрнәктәге мендәр тышлыклары чикте.

«Каз өмәсе» фестивале кысаларында төрле чаралар – бәйрәм ярминкәсе үтте, мастер-класслар күрсәтелде, күргәзмәләр оештырылды, «Шәҗәрә» бәйгесенә йомгак ясалды.

Ул көнне мөслимлеләр, район кунаклары каз шулпасы, кайнар ботка, тәмле коймак белән сыйланып, фестивальнең махсус кунаклары Алмаз һәм Зөлфирә Мирзаяновларның, район үзешчәннәренең җырларын тыңлап, рәхәтләнеп ял итте.



# ЭЧТӘЛЕК

## ТАТАР ДӨНЬЯСЫНЫҢ ТРАДИЦИОН МӘДӘНИЯТЕ ЯҢАЛЫКЛАРЫ




4 «Республиканың чигелгән картасы» – Татарстан Милли музее экспонаты

6 Татарстан осталары «РОСТКИ» бизнес-форумында катнашты

10 «Тылсымлы җеп» бәйгесенә йомгак ясалды


## ЗӘВЫКЛЫЛЫК БЕЗДӘН БАШЛАНА




12 Р. Мөхәммәтова **Солтан Салиев: «Минем милли киемнәр киелә икән, димәк, республика үсешенә үз өлешемне керткәнмен»**


## ҺӨНӘРЛЕ УЛМӘС...




22 Г. Кәлиева **Оста шәлчеләр – Балык Бистәсендә**

24 М. Сәләхова **Туембаш итекләре**



Түгәрәк уен

№4 (54 ) / 2024


*Халык зур ул, көчле ул, дәртле ул,*
*моңлы ул, әдип ул, шагыйрь ул.*
*Г. Тукай*


16+ Татар халык иҗатын яктыртучы мәгълүмати-популяр альманах

Гамәлгә куючылар:
Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы каршындагы Татарстан Республикасының мәдәният өлкәсендә инновацияләр һәм традицияләр саклау ресурс үзәге

Редколлегия:
Ирада Әюпова
Марсель Бакиров
Тәлгат Галиуллин
Дания Заһидуллина
Марс Тукаев
Фәрит Юсупов

Директор: Алсу Равил кызы Мифтахова
Баш мөхәррир: Рәзинә Әхтәм кызы Исмәгыйлева

Альманахның иҗат төркеме:
Гөлназ Латыйпова
Илнара Гәрәева

Дизайнер һәм биткә салучы:
Диләрә Нәүрузова

Альманах 2020 елның 13 ноябрендә элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр даирәсендәге күзәтчелек буенча Федераль хезмәт идарәсендә (Роскомнадзор) теркәлгән. Теркәлү таныклыгы ПИ № ФС77-79590. Журнал өч айга бер чыга. Бәясе ирекле.

Кәгазь форматы 60×90 ⅛.
Күләме 8 басма табак.
Басарга кул куелды: 10.12.2024
Чыгу көне: 15.12.2024
Заказ: 129. Тираж: 1000 экз.

Редакция һәм нәшер итүче:

420021, Казан, Тукай ур., 74 а.
Хатлар язар өчен адрес:
420015, Казан, Пушкин ур., 66/33
Телефон: 293-27-99.
E-mail: tugarakuen@mail.ru

«Фолиант» ҖЧҖндә бастырылды.
Казан, Восстание ур., 100, корп. 6130

Кульъязмаларга бәя бирелми, алар кире кайтарылмый.
Күчереп басканда, «Түгәрәк уен» альманахына сылтама ясау мәҗбүри.

**Тышлыкта:**
Модельер Солтан Салиев коллекциясеннән.



© «Түгәрәк уен», 2024

ӘДӘБИ МИРАС




26 Л. Мөхәммәтҗанова
**Татар фольклорында ырымнар**


МИФОЛОГИК МИРАС


31 Г. Гыйльманов
**Келәү – дога гына түгел**


БЕЗНЕҢ КИТАПХАНӘ





52 **Тапкыр кыз** *(Әкият)*


ХАЛКЫБЫЗНЫҢ КҮРКӘМ ЙОЛАЛАРЫ




35 Л. Хәкимова
**«Каурый бәйрәме» фольклор күренеше**


СӘХНӘ


40 З. Мөхәммәтшина
**Театр – үзе бер сихри дөнья**


БЕЗ, БЕЗ, БЕЗ ИДЕК...




54 **Таныш булыгыз: «АСЫЛЪЯР» музыка, җыр һәм бию ансамбле**

58 **Кышкы аланда** *(җыр)*


ХАЛКЫБЫЗНЫҢ КҮРКӘМ БӘЙРӘМНӘРЕ




46 Р. Мөхәммәтрәхимова
**Балык Бистәсендә – «Бистә шәле» бәйрәме**


БЕЗГӘ ЯЗАЛАР


50 Ф. Хәйриева
**Бай тарихлы Байсар**


ӨЙ КҮРКЕ – АШ




59 К. Насыйри
**Иршад Әл-Әтбиха**

60 **Күркә кәбабы**


ЯЛ СӘГАТЬЛӘРЕНДӘ


62 **Бергәләп бизибез!**

# «Республиканың чигелгән картасы» – Татарстан Милли музее экспонаты



Бу елның 3 ноябрендә Татарстан Республикасы Милли музеенда «Республиканың чигелгән картасы»н тапшыру тантанасы узды. Хәзер Татарстан осталары тарафыннан кулдан чигелгән республика картасы төп музей экспонаты булып исәпләнә. Аны теләге булган һәркем килеп карый ала.

Әлеге «Республиканың чигелгән картасы» проекты 2023 елда республикада игълан ителгән Милли мәдәниятләр һәм традицияләр елын матди гәүдәләндерү буларак гамәлгә ашырылды. Ул Татарстан хөкүмәте һәм республикабыз Рәисе Рөстәм Миңнеханов ярдәме белән үткәрелгән шул исемдәге республика акциясе кысаларында башкарылды.

Республикабызның 43 районы һәм ике шәһәр округында яшәүче чигүчеләр бик зур тукымада Татарстан картасы фрагментларын чикте. Биредә һәр муниципалитетның табигате һәм территориясе, тарихы һәм мәдәни традицияләре үзенчәлекләре исәпкә алынды. Проектта 23 яшьтән 70 яшькәчә булган 52 оста катнашты. Барлык 45 фрагмент та республика территориясендә кулланыла торган борынгы чигү технологияләреннән (биек/түбән тамбур, тоташтан чигү техникасы һәм келәм чигеше) файдаланып, кулдан эшләнде.

Тукымада табигать төсмерләрендә башкарылган традицион үсемлекле һәм геометрик бизәкләр сурәтләнгән. Осталар республикабыз территориясендә яшәүче төп халык: татар, рус, чуваш, мари, удмурт, мордваларның милли байлыгын сурәтләделәр. Татарстанның төп су байлыгы – Идел һәм Чулман елгалары рәсемнәре картаның үзара берләштерүче композицион элементы булып тора.

Картаны тапшыру тантанасында чигүче осталар төрле чигү техникаларына өйрәттеләр, каллиграфия һәм рәсем сәнгате буенча мастер-класслар үткәрделәр, музыкантлар уйнап, җырлар яңгырап торды.

Әлеге тантаналы чарада Татарстан Республикасы мәдәният министрының беренче урынбасары **Юлия Әдһәмова** катнашты.



*«Картада территория белән бәйле төп мотивлар сурәтләнгән. Чигүчеләр үз территорияләренең һәр кишәрлеген төшергәндә техника тарихына мөрәҗәгать иткән һәм аны камилләштергән. Проектның иң тәҗрибәле чигүчесе – 73 яшьлек ханым яшь буынга үз осталыгын күрсәтергә тырышкан. Алга таба бу картаның Татарстан Республикасы Милли музееның лаеклы экспонаты булачагына ышанам»,* – диде ул.



«Бүген без бер экспонатка баедык. Бу чигелгән карта – үз эшеңә, үз Ватаныңа карата мәхәббәт билгесе. Үз куллары белән нәрсә дә булса эшли белгән, үз эшләренең чын осталары мине һәрвакыт рухландыра. Бу очракта алар чигү эшен төрлечә үзләштергән: кемнәрнедер әниләре яисә әбиләре өйрәткән, кемнәрдер үзләре өйрәнгән. Бу гаҗәеп һөнәрне шулай буыннан-буынга тапшыра килгәннәр», – диде Татарстан Республикасы Милли музееның генераль директоры Алиса Вяткина.

*«Бу – зур вакыйга, чөнки республикабыз тарихында беренче буларак, Татарстан Милли музее экспозициясенең төп элементларыннан берсе булган карта төзелде. Әлеге проектка тотынганда алдыбызга бик күп бурычлар куелды. Дөресен әйткәндә, шактый гына проблемалар да ачыкланды. Чигүчеләр һәрбер районда да юк иде. Осталарны эзләү башланды, һәм ул уңыш белән төгәлләнде. Һәр район алдына уникаль эскиз эшләү бурычы куелган иде, бар кеше дә үз якларының тарихын белми булып чыкты. Нәкъ менә шуңа күрә дә бу карта аларны үз белемнәрен тирәнәйтүгә, дөньяга карашларын киңәйтүгә этәрде. Шулай ук районнарның мәдәни төсмерләре төрле булуга карамастан, картаның бердәм бербөтенне тәшкил итүе мөһим иде. Без моны булдырдык!»* – диде проектның фәнни консультанты **Гүзәл Вәлиева-Сөләйманова**, чигелгән карта төзүнең нечкәлекләре белән уртаклашып.



# Татарстан осталары «РОСТКИ» бизнес-форумында катнашты

БИЗНЕС-ФОРУМ 商业论坛
РОСТКИ 萌芽

2024 елның 14-15 ноябрендә Казанда «РОСТКИ: Россия һәм Кытай – үзара файдалы хезмәттәшлек» дип аталган II Халыкара форум узды. Бу форум – Россия һәм Кытай арасындагы эшлекле мөнәсәбәтләрне һәм мәдәният алмашуны ныгыту өчен оештырылган бик зур чара булды.

«РОСТКИ» форумы кысаларында «Казан ЭКСПО» Халыкара күргәзмә үзәгендә мәдәни экспозиция дә эшләде. Татарстанның мәдәни казанышы 5 тематик зонада: уртак мәдәниятләр зонасы, шулай ук «Агач», «Ут», «Су», «Металл» зоналарында тәкъдим ителде.

Татарстан Республикасы мәдәният министры Ирада Әюпова «РОСТКИ» Халыкара форумы кунаклары өчен «Russia China Expo» мәдәни экспозициясе буйлап экскурсия үткәрде. Экспозицияне Татарстан Республикасы Рәисе Рөстәм Миңнеханов та карады.

«Тарихи яктан безнең җиребез Көнбатыш белән Көнчыгыш арасына урнашкан. Бу юлдан товар төялгән кәрваннар гына узып калмаган, мәдәниятләр алмашу да барган. Безнең музыка (татар музыкасы турында сүз бара) һәм Кытай музыкасының нигезе бер – пентатоника. Мин бу охшашлыкның тарихи тамырлары тирәндәдер дип уйлыйм, һәм нәкъ менә шуңа күрә дә безнең бурыч – аларның киләчәген саклау. Барыгызга да яхшы һәм нәтиҗәле эш телим, ә иң мөһиме – мәдәниятне, якын күршеләрнең һәм еракталы халыкларның мәдәниятен өйрәнү һәм танып-белүгә якынрак килү. Нәкъ менә шул мәгълүмат иң нык дуслык күперләре төзелеше өчен материал булып тора», – диде «РОСТКИ: Россия һәм Кытай – үзара файдалы хезмәттәшлек» II Халыкара форумының мәдәни мәйданчыгы ачылышында Ирада Әюпова.




PARTICIPANT






Биредә ике көн дәвамында Татарстанның халык сәнгате һөнәрләре һәм декоратив-гамәли сәнгать әйдәүче осталары тарафыннан төрле мастер-класслар уздырылды, милли киемнәр күрсәтелде, концерт чыгышлары булды, фәнни һәм практик секцияләр һәм башкалар эшләп торды. Әлеге эшне оештыруда Татарстан Республикасының мәдәният өлкәсендә инновацияләр һәм традицияләр саклау ресурс үзәге дә актив катнашты.

Экспозиция үзәгендә Татарстан Республикасының халык сәнгате һөнәрләре эшләнмәләрен сату күргәзмәсе урнаштырылды. Биредә «Сәхтиян» ЖЧҖ эшләнмәләре («Казан җөе» техникасы белән башкарылган күн эшләнмәләр), «Ханбикә» фирмасының көмеш эшләнмәләре, осталар Алсу Зубкованың (керамикадан эшләнгән товарлар), Эльвира Фәтхуллинаның (алтынлап тегү техникасы белән кулдан чигелгән эшләнмәләр), Людмила





Волкованың (агачтан ясалган сувенирлар) сувенирлары һәм эшләнмәләре белән танышырга һәм аларны сатып алырга мөмкин иде.

Шулай ук күргәзмәдә Татарстан Республикасы Милли музее сувенирлары, кул остасы Альбина Нуретдинованың милли киемнәрдәге курчаклар сериясе, «Болгар керамика» брендының керамик савыт-сабасы һәм Ханты-Мансийск һөнәрләр үзәге осталарының кулдан башкарылган текстиль эшләнмәләре дә тәкъдим ителде.

«Агач» зонасында Татарстанның халык сәнгате һөнәрләре осталары урын алды. Алар форумда катнашучыларга һәм кунакларга төрле мастер-класслар тәкъдим итте:

- Казан (татар) җөе технологиясе буенча (Гөлия Сафина);
- элмәкле аппликация буенча (Әлфия Нурхаматова);
- тамбурлы чигү буенча (Альбина Стоянова);
- милли открыткалар ясау буенча (Диләрә Камалова);
- курайда уйнау буенча (Фарат Ханбәков);
- челтәр үрү буенча (Рәмзия Фәттахова, Елена Флюр);
- каллиграфия буенча (Гөлназ Исмәгыйлева);
- агачка бизәк төшерү буенча (Рәзидә Юсупова);
- агач кашыкларга һәм матрешкаларга бизәк төшерү буенча (Людмила Волкова).

Әлеге мәйданчыкта халык аеруча күп булды. Күп кенә кунаклар һәм форумда катнашучылар үзләрен оста ролендә сынап карарга һәм, Казан форумы турында истәлек итеп, үзләренең уникаль эшләнмәләрен (яулык чигү, элмәкле аппликация ярдәмендә брошка ясау, тамбур энәсе белән үрү, сувенирга бизәк төшерү, милли стильдә открытка ясау) тудырып карады.

Шулай ук биредә «Фарфор Сысерти» фабрикасының фарфор һәм фаянстан ясалган эшләнмәләр экспозициясе дә куелган иде. Бүген бу – үзләренең Свердловск өлкәсендә генә түгел, аннан читтә, бөтен Россиядә танылган традицион рус халык сәнгате һөнәре предприятиесе. 1994 елда аның продукциясе өлкәнең сәнгать-эксперт советы тарафыннан халык сәнгате һөнәрләре эшләнмәләре исәбенә кертелде. «Фарфор Сысерти» заводы уннарча төр савыт-саба житештерә: чәй һәм кофе сервизлары, вазалар, декоратив фигуралар, бизәнү әйберләре һәм башкалар. Продукциянең шактый өлеше – сувенирлар, алар арасында, мәсәлән, Урал әкиятләре мотивлары буенча эшләнгән скульптуралар да бар.

Һөнәрчеләр һәм рәссамнарның Халык сәнгате һөнәрләре ассоциациясе тарафыннан оештырылган «Мирас һәм традицияләр» күргәзмәсе дә халыкны битараф калдырмады. Анда ассоциация составына кергән осталарның кыйммәтле һәм ярымкыйммәтле ташлардан ясалган уникаль эшләнмәләре куелган иде. Күргәзмәне аның житәкчесе, «Уникаль Россия» Сәнгать һөнәрләре күргәзмә-форумының Оештыру комитеты рәисе Сергей Коломийцев тәкъдим итте.

# «Тылсымлы җеп» бәйгесенә йомгак ясалды



2024 елның 30 июленнән 30 октябренә кадәр дәвам иткән «Тылсымлы җеп» кулдан башкарылган бизәкле чигү эшләнмәләре республика бәйгесенә йомгак ясалды.

Әлеге бәйге Гаилә елына багышланган иде. Аны гамәлгә куючы – Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы, оештыручылары – Татарстан Республикасының мәдәният өлкәсендә инновацияләр һәм традицияләр саклау ресурс үзәге һәм «Татнефть-Мирас» тарихи һәм мәдәни мирасны саклауга булышлык итү үзәге. Бәйгенең максаты: халык сәнгате мәдәниятенә, Татарстан халыкларының матди-рухи мирасының аерылгысыз өлеше булган декоратив-гамәли сәнгать төрләренең берсе – чигүгә кызыксынуны арттыру.

Бәйгедә 95 оста катнашты, жюри карамагына алар тарафыннан 123 эш тапшырылды. Бу нигездә традицион чигү техникасын кулланып башкарылган эшләнмәләр иде.

Жюрига гаять зур эш йөкләнде, ул бәйгедә катнашучыларның осталык дәрәҗәләрен, тәкъдим ителгән эшләнмәләрнең сыйфатын һәм күптөрлелеген югары бәяләде.

**«Тылсымлы җеп» бәйгесенең җиңүчеләре:**

**I урын**
Ләйлә Галимова
Әлфия Нурхамәтова

**II урын**
Хания Гәрәева
Эльвира Фәтхуллина








**III урын**
Елена Коняхина
Алия Фаздалова

**Махсус приз**
Зөлфия Гыйльметдинова
Лилия Вәлиева
Гөлия Бәширова

6 декабрьдә «Тылсымлы җеп» республика бәйгесе җиңүчеләре «Традицион чигү: интерпретация ысуллары һәм формалары» дигән практик семинарда катнаштылар. Анда тәҗрибәле экспертлар хәзерге заманның традицион татар халык чигүе турында сөйләделәр һәм узган бәйгедә катнашучыларның эшләренә анализ ясадылар.

Шул ук көнне Н.И. Фешин исемендәге Казан сәнгать училищесында «Тылсымлы җеп» бәйгесенең җиңүчеләрен бүләкләү тантанасы булды.

Семинар кысаларында «Тылсымлы җеп» бәйгесе эшләнмәләренең күргәзмәсе дә оештырылды.





Яңалыклардагы фоторәсемнәр Татарстан Республикасының мәдәният өлкәсендә инновацияләр һәм традицияләр саклау ресурс үзәге архивыннан

# СОЛТАН САЛИЕВ:
## «МИНЕМ МИЛЛИ КИЕМНӘР КИЕЛӘ ИКӘН, *димәк, республика үсешенә үз өлешемне керткәнмен»*

*Рузилә МӨХӘММӘТОВА,*
*журналист*

**Республиканың рәсми чараларында булсынмы, зур кунаклар каршылагандамы, гүзәл кызларыбыз Матурлык конкурсларында Татарстанны тәкъдим иткәндәме – кайда гына булмасын, без Солтан Салиев эскизлары буенча тегелгән милли костюмнарны күрәбез.**

**Журналыбызның бүгенге кунагы – танылган дизайнер-модельер, Евразия этнодизайнерлары ассоциациясе вице-президенты, Мәскәү дизайнерлары берлеге премиясе лауреаты Солтан Салиев. Сүз уңаеннан, андый премия лауреатлары 34 кенә кеше һәм алар арасында Вячеслав Зайцев белән Валентин Юдашкин да бар иде.**

Солтан Кыргызстанда туып үскән татар егете һәм шушы татар мәдәниятеннән бераз читтәрәк үскән егетнең татар костюмын нечкә тоемлавына таң калырлык. Без Солтан белән нәсел тамырлары, хезмәт юлы турында сөйләштек.

«Тамырларым биредә: әтиемнең нәселе Башкортстанның Туймазы якларында гомер иткән, әнием ягыннан тамырларым Казаннан ерак түгел – Чүпрәле районының Кәкерле авылыннан. Бабам хәлле кеше булган: җәен иген иккән, кышка кергәч сәүдә иткән. Бөтен Урта Азияне әйләнеп, Һиндстан белән Кытайга кадәр барып җиткән. Ефәк юлы буйлап йөргән – бер җирдән





алган да икенче җирдә саткан. Кулакларны сөрү вакытында качып өлгергән, «Төнлә сезне алырга киләчәкләр» дигән хәбәр ишеткәч, гаиләсен арбага төягән дә чыгып киткән. Башта алар Грозныйда тукталып, беркадәр вакыт шунда яшәгәннәр, аннары Урта Азиягә килеп урнашканнар», – дип сөйли Солтан.

Союз таркалып, буталышлар башлангач, Урта Азияне үз ватаны иткән байтак татар гаиләләре күченеп китә. «Мин ни өчен икәнен дә әйтә алмыйм – тормыш начар түгел иде: җылы климат, тәмле ризык. Халыкны туздырып ату кемгәдер кирәк булгандыр инде... Бу безгә дә Татарстанга кайтып урнашу өчен бер этәргеч булды», – ди Солтан Салиев. Биредә танылу алган яшь модельер да, уңайлы тормышын калдырып, Казанга кайта. Монда ул эшчәнлеген яңадан гап-гади конструктор дәрәҗәсеннән башлап, басмалап-басмалап хәзерге статусына күтәрелә. Туксанынчы елларда яшәгән Казан кешесе «Киемнәр Данлы» һәм «Адонис» фабрикаларын хәтерлидер. Портфолиосын күргәч тә Солтанны «дүрт куллап» «Киемнәр Данлы»га эшкә алалар, әмма акчасыз заман бит, егет биредә озак эшли





*РЕСПУБЛИКАНЫҢ РӘСМИ ЧАРАЛАРЫНДА БУЛСЫНМЫ, ЗУР КУНАКЛАР КАРШЫЛАГАНДАМЫ, ГҮЗӘЛ КЫЗЛАРЫБЫЗ МАТУРЛЫК КОНКУРСЛАРЫНДА ТАТАРСТАННЫ ТӘКЪДИМ ИТКӘНДӘМЕ – КАЙДА ГЫНА БУЛМАСЫН, БЕЗ СОЛТАН САЛИЕВ ЭСКИЗЛАРЫ БУЕНЧА ТЕГЕЛГӘН МИЛЛИ КОСТЮМНАРНЫ КҮРӘБЕЗ.*





*СОЛТАН КЫРГЫЗСТАНДА ТУЫП ҮСКӘН ТАТАР ЕГЕТЕ ҺӘМ ШУШЫ ТАТАР МӘДӘНИЯТЕННӘН БЕРАЗ ЧИТТӘРӘК ҮСКӘН ЕГЕТНЕҢ ТАТАР КОСТЮМЫН НЕЧКӘ ТОЕМЛАВЫНА ТАҢ КАЛЫРЛЫК.*










алмый, акчалырак тәкъдимнәр була. Шулай да бирелдә эшләү киләчәк тормышына зур йогынты ясый – «Мисс Татарстана» оешмасы җитәкчесе Изольда Сахарова белән шунда таныша. Алар хәзергә кадәр дус яши, хезмәттәшлек итә. Солтан 15 ел чамасы «Мисс Татарстана» конкурсының рәсми дизайнеры булып тора.

«Рәсми затларны каршы алу өчен татар милли костюмнарын ясау тәкъдиме белән дә 2008 елда Изольда Генриевна чыкты. Бу җылы өс киемнәре иде – алар уңышлы булгандыр, чөнки хәзергә кадәр кулланыла», – ди ул.

Солтанның милли киемнәр дизайнеры булуы балачагына барып тоташа. «Әнием Казанда Сәүдә институтын тәмамлаган товаровед. Бирегә еш кына командировкаларга килеп, миңа китап-журналлар, үзенә, әбиләргә, туганнарга чигешле чүәкләр алып кайта иде. Мин бит әле әбиләр белән үстем – алардан да күп нәрсә өйрәндем. Минем ике әби дә тегә белә һәм икесенең дә яхшы тегү машиналары бар иде. Әти ягыннан әбием профессиональ тексә, әни ягыннан әби үзе өчен текте. Бездә әби-бабайларның матур киемле фоторәсемнәре дә саклана. Бабайның затлы түбәтәй кигән, кул таягы тоткан фотолары бар – аның зәвыгы да, затлы кием алу мөмкинлеге дә булган. Хәлле гаиләдә үскән әбинең дә затлы чулпылары, читекләре бар иде. Әби озын гомер кичерде – 100гә җитеп вафат булды. Аның сөйләгәннәре аудиоязмаларда сакланып калды. Балачагында әтисе белән арбага утырып ярминкәләргә йөрүен хәтерли иде. Миндә заманында Кәкерледән чыгып киткән бабамның түбәтәе дә саклана. Ул гап-гади – бәрхеттән тегелгән, формасын тотсын өчен ат кылы тыгып эчтән сырылган. Йомарласаң да үз формасына кайта. Менә шундый ул татар түбәтәе!» – дип балачак хатирәләрен дә яңартты дизайнер. Милли костюмнар иҗат итү өчен ул, бер яктан музей экспонатларын һәм галимнәрнең



*«КИЕМНӘР ДАНЛЫ»ДА ЭШЛӘҮ КИЛӘЧӘК ТОРМЫШЫНА ЗУР ЙОГЫНТЫ ЯСЫЙ – «МИСС ТАТАРСТАНА» ОЕШМАСЫ ҖИТӘКЧЕСЕ ИЗОЛЬДА САХАРОВА БЕЛӘН ШУНДА ТАНЫША. АЛАР ХӘЗЕРГӘ КАДӘР ДУС ЯШИ, ХЕЗМӘТТӘШЛЕК ИТӘ. СОЛТАН 15 ЕЛ ЧАМАСЫ «МИСС ТАТАРСТАНА» КОНКУРСЫНЫҢ РӘСМИ ДИЗАЙНЕРЫ БУЛЫП ТОРА.*



МИЛЛИ КОСТЮМНАР ИҖАТ ИТҮ ӨЧЕН УЛ, БЕР ЯКТАН МУЗЕЙ ЭКСПОНАТЛАРЫН ҺӘМ ГАЛИМНӘРНЕҢ МОНОГРАФИЯЛӘРЕН КУЛЛАНСА, ИКЕНЧЕ ЯКТАН, БҮГЕНГӘЧӘ САКЛАНГАН ШУШЫ ИСТӘЛЕКЛӘРЕ, НӘСЕЛ ТАРИХЫ ҺӘМ ХАТИРӘЛӘРЕ ЯРДӘМ ИТӘ.

монографияләрен кулланса, икенче яктан, бүгенгәчә сакланган шушы истәлекләре, нәсел тарихы һәм хатирәләре ярдәм итә.

«Минем алда тарихи костюм күрсәтү максаты тормый, – ди модельер. – Без милли костюмны 100 процентка кире кайтара алмыйбыз. Беркайчан да! Гасыр дәвамында без аннан киткәнбез һәм кире кайтмаячакбыз. Хәзер бит бөтенләй башка тормыш: андый күлмәкләр белән машинага утыруы да уңайсыз. Милли кием XX гасыр башында үзгәрә башлады – әйтик, татар кызы икәнлеген күрсәтеп тора торган нәни генә калфакчык, яки нәни генә изү элементы. Хәзер без шушы элементларны бүгенге көнгә яраклаштырырга һәм киләчәккә алып барырга тиешбез».

Солтан Салиевның «Кызлар хыяллары» дип аталган яңа милли коллекциясе уникаль дияр идем. Билгеле булганча, татар костюмының шәһәр һәм авыл юнәлеше бар. Ул яңа коллекциясендә шушы авыл күлмәге белән шәһәр образларын катыштыра алган. Татар костюмының барлык мәгънәгә ия элементлары ювелиркада башкарылган. «Сөембикәнең баш киемен картиналарда күргәнегез бардыр – менә шуны ювелир бизәнү әйбере итеп эшләдек», – ди ул.

Әлеге коллекцияне дизайнер, ТЮРКСОЙ чакыруы буенча, Төркия шәһәрләрендә – Измирда, Эфеста һәм Төньяк Кипрда күрсәткән. «Минем эшләремә Татарстаннан читтә игътибар күбрәк, әлеге коллекциямне дә шунда алып каласылар иде. Әмма мин аны анда сатарга теләмәдем. Күптән түгел бер музейдан әлеге коллекциянең бер өлеше булган челтәрле изүне сатуымны сорап язганнар, ни кызганыч, Татарстан музейлары түгел», – ди Солтан. Дөрес, гадәттә, коллекцияләренең бер өлешен шунда ук «Мисс Татарстана» оешмасы сатып ала икән. Әйтик, «Мисс Татарстана» конкурсында күрсәтелгән бәрхет күлмәкләр, мех якалар Солтан Салиев коллекциясеннән.

Тагын бер кызыклы мәгълүмат – Татарстан Республикасы Рәисе һәм башка җитәкчеләр кия торган күтәртмә якалы костюмнарның беренчел



*РЕСПУБЛИКАНЫҢ БЕРЕНЧЕ ЗАТЛАРЫ КАТНАШЫНДА ҮТКӘН БҮЛӘКЛӘҮ ТАНТАНАЛАРЫНДА ДА, МИЛЛИ КИЕМЛЕ КЫЗЛАР КАТНАШКАН БАШКА ТӨРЛЕ ОЧРАШУЛАРДА ДА ҮЗ КОСТЮМНАРЫМНЫ ТАНЫЙМ.*

эскизын Солтан Салиев ясаган. «Бу костюм версиясе миннән башланды. Миңа Татарстан Республикасының Министрлар кабинетыннан шәрыкъ илләренә бара торган түрәләргә костюм эскизлары ясау тәкъдиме белән чыктылар. Ир-ат һәм хатын-кыз киемнәре вариантларын эшләргә кирәк иде. Мин китаплар актарып, музейлар буйлап йөреп, интернеттан эзләнеп ир-ат һәм хатын-кыз образы ясадым. Аны Рөстәм Нургалиевичка күрсәттек. Презентациядә Әсгать Сәфәров та бар иде», – дип сөйли ул.

«Республика җитәкчеләре дә, зур кунакларны каршылаучы гүзәл кызларыбыз да (шул исәптән, БРИКС кунакларын чәкчәк белән каршы алучыларның бер өлеше дә) сезнең костюмнардан киенә. Сезгә моны күзәтеп тору ниндидер бер ләззәт бирәме?» – дип сорадым Солтан Салиевтан.

«Әйе, БРИКС кунакларын каршылаганда минем эскизлар буенча тегелгән костюмнар бар иде. Республикага килгән зур кунаклар Татарстан җиренә аяк баскач иң элек матур милли киемнәрдән киенгән кызларыбызны күрә. Бу республиканың йөзен билгели.

Универсиадада да минем костюмнар белән кунакларны каршыладылар, җиңүчеләрне бүләкләделәр. Су спорты төрләре буенча халыкара турнирда да кунакларны каршы алучыларда минем костюмнар иде. Аларның эскизлары Россиядә генә түгел, Франциядә расланды. Хәзер ул костюмнарны Милли музейда күрдем.

Республиканың беренче затлары катнашында үткән бүләкләү тантаналарында да, милли киемле кызлар катнашкан башка төрле очрашуларда да үз костюмнарымны таныйм. Миңа шалтыратып: «Ой, Солтан, бу бит синең костюмнар», – диюләре күңелгә рәхәтлек бирә. Димәк, мин республика казанышларына үз өлешемне керткәнмен», – ди дизайнер-модельер Солтан Салиев.

Фоторәсемнәр Солтан Салиевның шәхси архивыннан

# Оста шәлчеләр – Балык Бистәсендә

*Гөлфирә КӘЛИЕВА,*
*Күгәрчен авылы Мәдәният йорты сәнгать җитәкчесе*



2024 ЕЛНЫҢ 1 АПРЕЛЕНДӘ ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ РАЙОННАРЫ АВЫЛ МӘДӘНИЯТ ЙОРТЛАРЫ БАЗАСЫНДА «МӘХӘЛЛӘ» ИҖАТ КИҢЛЕГЕ» ПРОЕКТЫ БАШЛАНЫП КИТТЕ. БИРЕДӘ СӘНГАТЬНЕ БӘЯЛИ БЕЛҮЧЕЛӘР ҺӘМ ЯРАТУЧЫЛАР – ТУКУЧЫЛАРНЫҢ, ЧИГҮЧЕЛӘРНЕҢ, КИЕЗ БАСУЧЫЛАРНЫҢ, АГАЧКА УЕП РӘСЕМ ЯСАУЧЫЛАРНЫҢ ҺӘМ ҮЗЛӘРЕ КЫЗЫКСЫНГАН ЮНӘЛЕШЛӘР БУЕНЧА БАШКА КЛУБ БЕРЛӘШМӘЛӘРЕ КАТНАША.





Проект бүгенге көндә дә дәвам итә һәм биредә катнашучы иҗат мәйданчыклары, клуб берләшмәләре Татарстан Республикасы Хөкүмәтенең 250000 сумлык Грантына ия булдылар. Җиңүчеләр арасында Балык Бистәсе районының Күгәрчен авылы клубы каршында эшләп килүче «Бистә шәле» иҗат мәйданчыгы һәм Кукмара районының Туембаш Мәдәният йорты каршында эшләп килүче «Туембаш итекләре» клуб берләшмәсе дә бар.

Балык Бистәсендә гомер-гомергә тырыш, уңган халык яши. Алар балык тоту, үрчетү белән шөгыльләнәләр. Һөнәрчелеккә, кәсебкә килсәк, бистә шәлчеләрен дә беркем уздыра алмый.

Шәл бәйләү тарихы XX гасырның 20нче елларында Күгәрчен авылында башланган дип фаразлана. XIX гасырда ук инде кешеләр сарык йоныннан оекбашлар, бияләйләр, шарфлар бәйләгән. Бизәксез шәлләр бәйләү осталыгын Күгәрчен авылына беренче дипломлы укытучы Зәйтүнә Яруллина алып килгән. Соңрак ул Кыям мулла Шәрәфиевның хатыны була. Ул кызларны шәл бәйләү серләренә өйрәтә. 30нчы елларда сарык йонына, йомшаграк һәм матурраклы булсын өчен, куян мамыгы да куша башлыйлар. 60нчы еллардан күгәрченлеләр башта Казахстаннан, соңрак Донбасс, Ростов, Волгоградтан бик йомшак кәҗә йоны кайтарталар, шәлләр тагын да матурраклы һәм сыйфатлырак була бара, аларның бу үзенчәлекләре еллар дәвамында саклана. Шәл бәйләү һөнәре татарлар гына түгел, руслар да яши торган башка авылларга да тарала.

Заманында «мең душлы» дип йөртелгән, үзенең данлыклы шәл бәйләүчеләре белән танылган Күгәрчен авылы халкы бүген ни белән шөгыльләнә диярсез?

Әйе, Күгәрчен авылында бүген дә шәл бәйлиләр. Авылга килен булып төшкән һәр хатын-кызны шәл бәйләү серләренә өйрәтәләр. Зәйтүнә апа чорындагыча, сарык йоныннан, яисә сарык йонына куян мамыгы кушып түгел, матур, нәфис шәлләрне кәҗә мамыгыннан бәйлиләр.

Яшь буынны әлеге шөгыльгә тарту, кызыксындыру максатыннан Күгәрчен авылы мәдәният хезмәткәрләре, китапханәчеләр, Мәдәният йорты каршында эшләп килүче «Зөләйха» өлкәннәр оешмасы һәм «Сәрбиназ» балалар фольклор коллективы әгъзалары «Мәхәллә» проекты кысаларында «Бистә шәле» иҗат мәйданчыгы булдырдылар. Бу һөнәрнең төп асылын, тәртибен өйрәнгән әбиләр, «Зөләйха»лылар, яшь буынны кызыксындыру өчен төрледән-төрле чаралар уздыралар – мамык тетү, эрләү, җеп чорнау, бәйләү, шәлне киеру, шәл бәйләү серләренә өйрәтәләр, мастер-класслар күрсәтәләр. Иҗат мәйданчыгына «Сәрбиназ» балалар фольклор коллективы гына түгел, мәктәп укучылары да бик теләп килә. Җәй айларында әби-бабайларына кунакка кайткан шәһәр балалары да катнаша.

Бүгенге көндә иҗат мәйданчыгына барлыгы 25 кеше йөри. Шуларның 12се өлкән буын булса, калганнары – балалар. Киләчәктә «Бистә шәле» иҗат мәйданчыгы Күгәрчен авылының гына түгел, район яшьләрен, балаларын да үзенә җәлеп итсен иде.

Автор фоторәсемнәре

# Туембаш итекләре

*Миләүшә СӘЛӘХОВА,*
*Кукмара районы Мәдәният йорты методисты, «Туембаш итекләре» проекты авторы*



ЭЛЕК ЧИГҮ, БӘЙЛӘҮ, ТЕГҮ КЕБЕК КУЛ ЭШЛӘРЕНӘ, ХАТЫН-КЫЗ ҺӨНӘРЛӘРЕНӘ АУЛАК ӨЙЛӘРДӘ, КИЧ УТЫРГАНДА ӨЙРӘНГӘННӘР. БҮГЕНГЕ КӨНДӘ АВЫЛ МӘДӘНИЯТ ЙОРТЛАРЫНДА КҮП ТӨРЛЕ БЕРЛӘШМӘЛӘР ЭШЛӘП КИЛӘ. БИРЕДӘ ХАЛКЫБЫЗНЫҢ МИЛЛИ ҺӨНӘРЛӘРЕН ЯҢАРТУ, ЯШЬ БУЫНГА ТАПШЫРУ МАКСАТЫННАН ТАМБУРЛЫ ЧИГҮ, МИЛЛИ БИЗӘНҮ ӘЙБЕРЛӘРЕ ЯСАУ, КАЛФАК ТЕГҮ БУЕНЧА ТӨРЛЕ МАСТЕР-КЛАССЛАР ОЕШТЫРЫЛА.

Әлеге берләшмәләр өлкән буын белән үсеп килүче буын арасында тәҗрибә уртаклашу, халкыбызның милли үзенчәлекләрен, гореф-гадәтләрен, һөнәрләрен өйрәтү урыны да булып тора.

2024 елның 1нче апреленнән эшләп килүче «Мәхәллә» проекты кысаларында Кукмара районының Туембаш мәдәният йортында «Туембаш итекләре» («Шерстяные истории») клуб берләшмәсе эшли башлады.

Беребезгә дә сер түгел, бүгенге яшь буын буш вакытын телефон, компьютер каршында уздыра. Алар әби-бабаларының гореф-гадәтләреннән, халкыбызның милли традицияләреннән ераклаша бара. Кайбер һөнәрләрне белүче осталар да көннән-көн олыгая, сирәгәя. Кукмара районы элек-электән итекләре, итекчеләре белән дан тоткан. Бүгенге көндә Туембаш



авылында итек басу эше белән һәр гаилә кызыксына, бигрәк тә өлкәннәр шөгыльләнә.

«Туембаш итекләре» клуб берләшмәсендә Мәдәният йорты җитәкчесе Минзәлия Хафизова белән сәнгать җитәкчесе Рәмзия Нигъмәтҗанова, Туембаш авылының уңган остабикәләре белән берлектә, үсеп килүче буынга фелтинг техникасын кулланып, итекләрне төсле йоннар белән матур итеп бизәргә, йонны сабынлы су белән түшәү техникасын кулланып, төрле кул эшләнмәләре иҗат итәргә өйрәтәләр.

Иң мөһиме бередә яшь буынга җирлекнең үзенчәлекле һөнәре генә түгел, милли үзаң да тапшырыла. «Туембаш итекләре» клуб берләшмәсенең мөһим бурычларының берсе – итекләрне милли төсмердә бизәргә өйрәтү торса, икенчесе шушы техниканы кулланып ясалган продукция белән төрле күргәзмәләрдә катнашу, аларны сатып алучылар игътибарына тәкъдим итү. Бүгенге көндә клуб берләшмәсе әгъзалары район, башкала Сабантуйлары вакытында, райондагы «Җәйге променад» кысаларында узган кичке уеннарда, яшьләр көнендә, матур чараларда күргәзмә һәм мастер-класслар белән катнашалар. Казан шәһәрендә 30нчы август – Татарстан Республикасы көнен билгеләп үтүгә багышланган чарада да матур күргәзмә оештырды алар.

Бүгенге көндә «Туембаш итекләре» клуб берләшмәсендә итек бизәү техникасын 14 бала, 4 олы кеше үзләштерә. Төрле чаралар вакытында узган мастер классларда әлеге һөнәр үзенчәлекләре белән 300дән артык кеше танышкан.

Бүгенге көндә авыл клубларында шундый берләшмәләр оештыру – буыннар чылбырын тоташтыруны, ата-бабаларның кыйммәтле мирасын саклауны тәэмин итә.

Автор фоторәсемнәре



# ТАТАР ФОЛЬКЛОРЫНДА ЫРЫМНАР



*Лилия МӨХӘММӘТҖАНОВА,*
*филология фәннәре докторы, доцент, Татарстан Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының баш фәнни хезмәткәре*

**Борынгы төркиләрдә һәм аларның варислары булган татарларда фольклор жанрлары системасы формалашкан. Аларның бер өлеше башка халыклар иҗатындагы шундый ук жанрлар белән универсаль характерда булса, татарларның рухи тормыш үзенчәлекләренә бәйле барлыкка килгән яисә этник тарихына бәйле бик нык үзгәреш кичереп, башка юл алып үскәннәре дә бар.**

Татар фольклорында өстенлек иткән эпик, лирик, лиро-эпик жанр әсәрләрен иҗтимагый-эстетик функцияләре, композициясе, төзелеш-структурасы, тематикасы һәм эчтәлеге җәһәтеннән берләшкән төркемнәрдә күзәтү сүз сәнгате буларак татар халык иҗатын һәм аның үзенә генә хас үзенчәлекле якларын тулысынча күзаллау мөмкинлеге бирә.

Татар халык иҗаты әсәрләре күп кенә мәдәни һәм тарихи үзенчәлекләргә ия. Гасырлар дәвамында яңа фольклор формалары барлыкка килә барган, халык авыз иҗаты жанрларының башка заманныкыннан аерылып тора торган системасы формалашкан. Әсәрләрдә халыкның тарихи үткәне генә түгел, ә аның эчке дөньясы, рухи кичерешләре дә алгы планга чыккан, болар барысы да фольклорның иң үтемле жанрларында гәүдәләнеш тапкан.

## НӘРСӘ УЛ ЫРЫМ?

**Ырымнар** – фольклорның сихер, им-том, сихри сүз һәм хәрәкәт көченә ышану белән бәйле калыплашкан гыйбарәләрдән торган борынгы жанры. Алар татарларның исламга кадәрге үк тормыш рәвешенә барып тоташа торган үрнәкләр дип карарга тулы нигез бар. Ырымнарны бик борынгы заманнардан ук килә торган хорафатларга, ышануларга нигезләнгән гадәт дип аңлатырга мөмкин. Ырымнар – аерым хәлләрнең киләчәге уңышлы булуны яисә уңышсыз тәмамлануның алшарты. Фольклор жанры буларак, ырымның төп хасияте шунда: анда үзәктә магик шигъри сүз тора, ягъни алар – сихри көчкә ия телдән башкарыла торган кыска шигъри әсәрләр. Ырым сүзләре билгеле бер эмоциональ көчкә ия дигән ышану яши.

Ырымнар бары тик утилитар әһәмияткә ия. Аларны кулланып, сөйләүче-ырымчы уңышка ирешергә, мәхәббәт, җиңү һәм башкаларга китерергә өметләнә. Баштарак ырымнарда йола-башкару элементы зур урын алган булса, әкренләп аларда гамәл элементы югалган, ырымнар сүз сәнгатенә кадәр гадиләштерү тенденциясе алганнар. Әмма шул ук вакытта ырымнар билгеле бер сәбәп уңаеннан гына башкарылган. Ырымның төп үзенчәлеге – сүзнең магик көченә ышану.

Тематик яктан ырымнарның аграр (яхшы уңыш җыеп алуны теләп башкарыла торган); хуҗалык-көнкүреш (мал-туар үрчемле, йортта бәрәкәт булуны теләп үтәлгән); дәвалау (төрле чирләрдән, йокысызлыктан котылуны күздә тота, табиблык функциясен үти), мәхәббәт (егетне-кызны кавыштыру я аеру, ирне яки хатынны үзеңә ныграк карату максаты күздә тотыла); төрле бәлаләрдән саклау яисә киресенчә бәлагә юлыктыру (зур вакыйгалар алдыннан укылып, ахыргы нәтиҗәнең уңай яисә тискәре булуына йогынты ясый) ырымнары дигән төрләре була.

«Аллаһы куәт бирсен, җаныңа саулык бирсен!», «Армый эшләгез, сары май тешләгез!», «Авызыңа бал да май!», «Авызың белән әйт, борының белән тарт!», «Авызыңнан җил алсын, илтеп куеныңа салсын!», «Җылы авызыңнан – җылы куеныңа!», «Арпаң-көрпәң аш булсын, тамагыңа таш булсын!» – эчтәлеге һәм формасы ягыннан көндәлек тормышыбызда еш очрап торган әлеге тезмәләр борынгы ырымнарны хәтерләтә, болар – кеше язмышына йогынты ясап әйтелгән ырым текстларына якын торучы гыйбарәләр.

Ырым текстлары үзләренә хас логикага, фикерләү үзенчәлекләренә ия. Композициясе белән эпик (хикәяләү), императив (боерык яки үтенеч рәвешендә), метафорик (чагыштыруга нигезләнгән) һәм диалогларга корылган ырымнар билгеле. Ырымнарда гадәттә конкрет теләк әйтелә, аннан соң ырымчы үзе табына торган көчләргә, шул исәптән көнкүреш, мифик, дини, фантастик, антропоморфик образларга мөрәҗәгать итә, аларны ярдәмгә чакыра, метафорик юл аша көчләрне чынбарлыкка күчерә, үзенең теләк-үтенечен кат-кат ныгыта.

## УТ АНАСЫН НИЧЕК ТУКТАТЫРГА?

Татарстанның Тукай районы Мәләкәс авылында Ф. Баязитова тарафыннан язып алынган түбәндәге ырым янгынны туктатырга теләп әйтелгән:



*«Ут анасы күк була,*
*Ут анасы сары була,*
*Утның кызы камил була,*
*Кызына калгач кызу була,*
*Ут, уйнама, уйнама!*
*Ут, уйнама, уйнама!».*

Бу сүзләр әле генә янгын чыккан урынны өч кат әйләнеп чыгып әйтелгән.

Еш кына ырымнарның төп алымы – гиперболик чагыштыру, эпитетлар (тимер теш, камыр теш; яңа тән, иске тән; кара урманда кара чыршы; сары ут анасы; утның кызыл кызы; ишектән дә, тишектән дә керүче, күгәрчен кебек гөрләп, кыр казы кебек тезелеп килүче кот һәм башкалар), синтаксик һәм лексик кабатлаулар. Ырым поэтикасында ритм билгеле бер сөйләм кисәкләренең чиратлашуына нигезләнә. Ырым текстларын халык теленнән язып алу бик катлаулы эш, объектив сәбәпләр ырымнарны кеше күзеннән һәм колагыннан яшерен башкаруны таләп иткән.

Ырымнарның барлыкка килүе татарларның әле исламгача ук булган борынгы ышануларына бәйле. Мөселманлык кабул иткән татарларга ислам тәэсире бик көчле була, әлбәттә. Исламгача дәвер ырымнары әкренләп дин кануннары белән кысрыкланса да халык тормышыннан бөтенләй юкка чыкмаган. Мәҗүсилек чорларыннан ук килә торган, җаһилият ышануларына бәйле кайбер ырымнар, искереп, халык тормышыннан төшеп калсалар, кайберләре ислам йогынтысында зур үзгәрешләр кичереп, яраклашканнар. Ислам белән каршылыкка керми торган борынгы ырым текстлары халыкта бүгенге көндә дә очрап куярга мөмкин. Бу исә ырымнарның функцияләре гаять төрле икәнлекне һәм кайберләренең ислам кагыйдәләренә дә уңышлы яраклаша алганлыгын ассызыклый.

Вакыт барган саен ырымнарның тематикасы һәм проблематикасындагы, образлар символикасы, халыкчан сурәтләү-картина тудыру алымнары һәм структурасындагы үсеш-үзгәрешләр кешелекнең чорга хас аңы дәрәҗәсендә яңарыш кичерә барган. Халыкның теләк-омтылышларын тормышка ашыру һәм танып-белү офыклары киңәю белән бәйле рәвештә, татар фольклорында ырым текстлары әкренләп югала бара. Борынгылыкны чагыштырмача яхшы саклаган хәлдә, татарларның ырым фольклорын бүгенге көндә шактый актив жанр дияргә мөмкин.







## ЫРЫМ ТЕКСТЛАРЫ ДА – МИРАСЫБЫЗ

Халыкның фольклоры аша аның мәдәни барышын, тарихи хәтерен танып белергә мөмкин. Фольклор жанрлары һәм аларга караган аерым үрнәкләр үзләрендә тарихилык, миллилек, халыкчанлык, сәнгатьлелек кебек сыйфатларны берләштерүе белән бергә, татарларның башка халыклар белән охшаш һәм алардан аермалы якларын да күрсәтә. Сакланып калган ырым текстлары татарларның үткән юлын ачыклый, милли холык образын тергезүдә, үзбилгеләнүдә, киләчәкне билгеләүдә турыдан-туры катнаша торган компонентлар буларак әһәмиятле. Татарларда очрый торган ырым текстлары поэтикасына фольклорга хас традицион стиль, мотив һәм сурәтләү чаралары, образлар хас. Бу төр ядкәрләр – мәҗүсилек чорында ук мәгълүм булып, мөселманлык чорында исламга сыенып, үзенчәлекле этник йөзебезне саклап калырга ярдәм иткән кызыклы һәм күтәрелсә мирас. Татар халкындагы ырымнарның характерына һәм вазыйфасына карап, аларга бәйләнешле текстлар формалашкан, алар билгеле бер чәчмә яисә сирәк очракларда тезмә калыпка салынган, композицион яктан бер бөтен хәлгә килгән. Мондый төр фольклор үрнәкләре бүгенге көндә фәнни экспедицияләрдә татарлар яши торган төрле төбәкләрдә язып алыналар. Игътибарыгызга соңгы ун елда Татарстан Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты тарафыннан оештырылган комплекслы фәнни экспедицияләрдә халык иҗаты юнәлешендә язып алынган текстларны тәкъдим итәбез.

### *«Иске – яңа башына!»*

Иске, тузып беткән тапочкиларны өйдә тотарга ярамый, алар тискәре көчләрне үзенә тартып тора. Өйдә ертык киемнәрне дә тотарга ярамый, ертык булмаса, кими торган кием булса да тотарга ярамый. Тотып атасы искене. Атканда әйтәсе: «Иске – яңа башына! Иске – яңа башына!»

### *«Миңа тимә!»*

Елгада су кера торган идек. Суга кергәнче яр буенда әйтәсең :

«Су анасы – сылу сакал,
Җир анасы – җирән сакал,
Күк анасы – көрән сакал!
Миңа тимә! Миңа тимә!
Мине ашама! Мине эчмә!»

**Бөгелмә районы Суык Чишмә авылыннан Әнисә Миңнегәрәй кызы Гарифуллина (1932 елгы).**

## *Зыяннан котылыр өчен – йомырка*

Бер йомырканы каты итеп пешерергә, аны алып, йорт-курадан ераккарак китәргә. Кеше бик йөрмәгән, тыныч урынга барырга. Шунда йомырканы мондый сүзләр әйтеп күмеп куясы: «Яман күздән, яман нияттән, көнләшүдән күмәм. Саклау-яклау алырга, агулы көнләшүдән, зыяннан котылырга килдем. Нәрсә белән килдем, шуны монда калдырам. Ничек иттем, шулай эшләдем!» Шуннан соң өйгә кайтып китәсе, артка борылып карарга ярамый.

**Бөгелмә районы Сугышлы авылыннан Нәҗибә Насыйр кызы Габдрахманова (1942 елгы). Тумышы белән Баулы районы Кызыл флаг авылыннан, 1964 елдан Сугышлыда яши.**

## *Төбәп әйтелгән начар сүз тәэсиреннән ничек арынырга?*

Талашырга, кычкырышырга ярамый. Әгәр талашкансың икән, ага торган су астында басып торырга кирәк, я госел алырга – тискәре энергия чыксын өчен. «Бисмиллаһ» дип кабатлау тиеш.

Сиңа кычкырып яхшы теләк теләсәләр, «Әйткәнең килсен!» дияргә кирәк. Тискәре сүз ишетсәң, пышылдап кына «Кире китсен!» диясе, я «Каян килсәң, шунда кит!» дияргә өчәр кат. Каргасалар әйтергә кирәк шул минутта ук: «Үзеңә кире кайтсын! Үзеңә теләгәнең булсын! Үзеңнеке – үзеңә! Бер нәрсәңне дә алмыйм, капкам ябык!».

Тискәре көчләр тәэсиреннән су белән котылырга кирәк. «И Раббым, мине яман күздән, яман сүздән сакла!» диясе.

Инә, төймә, тырнак ише шакшыга юлыксаң, «Миңа дип ясалганны үзенә кайтар, кем ясаган, шуңа китсен!» дип кат-кат кабатлап, өйдән читкә алып барып күмәргә. Аннан кулларны юарга.

Дәшми генә тоттырган әйберне алма. Шикләнгән кешедән дә әйбер алу ярамый. «Нәрсә дип бирмәкче булса да үзенеке үзенә булсын!» дияргә кирәк.

**Бөгелмә районы Сугышлы авылыннан Гөлсинә Шәфыйк кызы Игитисамова (1950 елгы), тумышы белән Лениногорск районы Сугышлы авылыннан.**

## *Ырым*
*(балалар фольклоры)*

Яулыгын я бүтән берәр нәрсәсен тартып аласың да ачуыңны китергән кешенең, ике аяк арасыннан үткәреп, «Мә яулыгыңны, ырымладым», – дисең. Кире бирәсең. Ырымлаганда болай әйтәсең:

«Әфсен-төфсен,
Бер бидрә кан аксын!»

Яулык хуҗасы үртәлә инде, ырымланды әйберем дип курка. Шаярту инде.

**Самара өлкәсе Похвистнево районы Красный мост авылыннан Рәйсә Гариф кызы Йосыпова (1932 елгы).**

## *Аякка басма!*

Ялгыш аякка басса берәрсе, кабат үзенекенә басып аласың, әнкәң-әткәң үлмәсен, дип.

**Мөслим районы Үрәзмәт авылыннан Венера Мияссәр кызы Нургалиева (1970 елгы).**

## *Җомга көн – иң зур бәйрәм*

Җомга турында эш эшләргә ярамый, эшең ут булып янар. Ислам дөньясында җомга көн – иң зур бәйрәм санала.

Суга пес итмә, шул җирең (әниләр аны чыпчыгың, мәчтиең дип әйтәләр иде) черер.

Олылар сөйләгәндә катышма, телең үсеп, авызыңа сыймый башлар.

Кояntәне атлап чыкма, кыярак (төер, биз) чыгар.

**Мөслим районы Вәрәшбаш авылыннан Тәзкирә Газетдин кызы Низамиева (1943 елгы).**

## *Сөт теше*

Баланың сөт теше төшкәнен күргән кеше: «Тычканга – камыр теш, сиңа – тимер теш», – дип теләк тели. Сөенче итеп хәер бирә, сөт тешен ярыктан базга сала.

**Чиләбе өлкәсе Уй районы Әмин авылыннан Фәнүзә Хаҗимөхәммәт кызы Биккулова (1959 елгы), Башкортстаннан күчеп килеп, биредә 1995 елдан яши.**

Рәсемнәрдә: Лилия Мөхәммәтҗанова Татарстан Республикасының Бөгелмә районы информантлары белән әңгәмә вакытында. Авторның шәхси архивыннан

# КЕЛӘҮ – *дога гына түгел*

*Галимҗан ГЫЙЛЬМАНОВ,*
*язучы, әдәбият белгече*



**Өй иясе – кешеләргә иң якын торган түбән рух. Шуңа күрә дә кеше аның белән башка рух-ияләргә караганда ешрак очраша. Өй ияләре хакындагы мифларның күп булуы да шуның белән аңлатыла.**

Күңел теле – дога теле. Дога – рухи, илаһи категория. Рухият дога тәгълиматына, дога фәлсәфәсенә һәм дога поэтикасына нигезләнә. Күңел дөньялык, табигать белән, аеруча югары һәм түбән рухлар, ияләр, «ата»лар, «ана»лар, ирәннәр, башка илаһи һәм ярым илаһи затлар, изгеләр, борынгы нәсел бабалары белән дога телендә сөйләшә, аралаша. Һәрхәлдә, борынгылыкта шулай булган. Безнең бабаларыбыз да кайчандыр әнә шундый «дога теле» белән сөйләшкән. Ислам динен кабул иткәнчегә кадәр үк ниндидер рәсми дин кысаларына кереп бетмәгән рухи тәгълимат булган, аны без «тәңречелек тәгълиматы» дип әйтергә күнеккәнбез. Димәк, мәҗүси догалар булган. Борынгы мәҗүси догаларны, аларның эчтәлегенә, максатына карап, берничә юнәлештә өйрәнергә мөмкин: келәүләр (теләкләр), арбаулар (мактау), тулгаулар (алкышлау), җыр-типсәүләр, антлар, каргышлар... Болардан тыш ниндидер тема белән бәйле догалар (туй, бала, йорт, яу, чәчү, имләү, юрау, үлем, бәхет...). Әфсеннәр, ырым такмаклары (кешенең рухиятенә, психикасына, язмышына, сәламәтлегенә тәэсир итәргә тырышу белән бәйле дога элементлары) аерым өйрәнелергә лаек. Халык телендә тагын бер дога формасы сакланып калган: табигать теле, яу теле, тимер теле, ут теле, җан теле, кан теле, чир теле һәм башкалар. Шуны да искәртергә кирәк: бу догаларның барысы да ниндидер шаукымлы-магик йола кысаларында башкарылган, аяныч, аларның күбесе инде онытылган.

Сүзебез алда телгә алган догаларның КЕЛӘҮ җыры (жанры) хакында.

КЕЛӘҮЛӘР – мәҗүсилек чорында, бигрәк тә тәңречелек тәгълиматы йолаларын башкарганда әйтелә, укыла торган көйле догалар. «Келәү әйтү», «келәү итү» гыйбарәләре белән телгә кереп калганнар. «Келәү» – «теләү» сүзеннән алынган. («Теләү» сүзе үзе «тел» сүзеннән.) «Теләк» сүзе дә шушы тамырга килеп тоташа. «Келәү» сүзе хәзерге татар телендә кулланылмый диярлек, гадәттә, мәҗүси йолалар белән бәйле чараларда телгә алына; «теләү» сүзен исә бүген ислам дине белән кергән «дога» сүзе алыштыра. Мөселман динендә булмаган

төркиләрдә әле дә бу атама саклана: керәшен татарларында чиркәүдә дога уку «келәү итү» дип йөртелә, чувашларда «кел» сүзе «дога» дигәнне белдерә. «Келәү садакасы» да булган, ул «келәү акчасы» дип йөртелгән.

Шуны да искәртергә кирәк: борынгылыкта булган табыну, ялвару мәгънәсен югалтып, соңгырак дәверләрдә теләк теләү җыруларына яисә балалар телендәге такмакларга әверелеп яшәгән.

Бу сүз сирәк кенә булса да матур әдәбиятта очрый. Мәсәлән, Татарстанның халык шагыйре Клара Булатова бу сүзне үзенең беренчел, ягъни мәҗүси мәгънәсендә куллана:

*Йөрәгемнең иң түрендә туган*
*Иң ягымлы йомшак җырларын*
*Афәтләрдән саклый торган изге*
*Келәү итеп сиңа юлладым.*

Чынлыкта, бүген безгә мәгълүм келәүләр – тезмә-шигъри калыпларда формалашкан, борынгылыктан килгән ялвару мәгънәсен күпмедер саклап калган мәҗүси теләкләр; аларны халык иҗатындагы кайбер җыр-такмак-такмаза традицияләре белән дә, ырым, им-том текстлары яисә әфсен-төфсеннәр белән дә чагыштырырга мөмкиндер. Ахыр чиктә, аларның барысы да теләк теләүгә һәм магик-мәҗүси дога йолаларына кайтып кала. Бик сирәк кенә келәү традициясенә образлашкан мифик персонажлар – иябәр, рухлар да килеп керә. Адлер Тимергалин үзенең «Миллият сүзлеге»ендә керәшен татарларының мәшһүр шагыйре Яков Емельяновтан шундый өзек китерә: «Бүген күргән төшем дә келәүләр турында булды. Өсләренә ак кигәннәр безнең өйгә тулды».

Мәгълүм булганча, һәр мәҗүси доганың үз йоласы бар. Һәм һәр келәү-дога билгеле бер хәрәкәт ритмында әйтелә, җырлана, көйләнә, башкарыла. Димәк, келәү әйтүнең борынгы шаманлык традицияләре белән дә ниндидер уртак ягы бар.

> «
> КҮҢЕЛ ДӨНЬЯЛЫК, ТАБИГАТЬ БЕЛӘН, АЕРУЧА ЮГАРЫ ҺӘМ ТҮБӘН РУХЛАР, ИЯЛӘР, «АТА»ЛАР, «АНА»ЛАР, ИРӘННӘР, БАШКА ИЛАҺИ ҺӘМ ЯРЫМ ИЛАҺИ ЗАТЛАР, ИЗГЕЛӘР, БОРЫНГЫ НӘСЕЛ БАБАЛАРЫ БЕЛӘН ДОГА ТЕЛЕНДӘ СӨЙЛӘШӘ, АРАЛАША
> «

Келәү традициясе белән бәйле йолалар хакында хәбәрләр бүгенге көнгә кадәр килеп җиткән. Адлер Тимергалин «үлдүкләр келәү» (үлекләр келәү) дигән борынгы йола хакында яза. Һәр елны көзен (25 октябрьдә), кардәш-ырудашлар җыелып, үлгәннәрне искә ала торган булганнар. Өйдәме, каберстандамы, келәү әйтешеп, җырлашып утырганнар, каберләрне караганнар, хәер-садакалар өләшкәннәр, чардуганнарны төрле төстәге чүпрәк-тасмалар белән бизәгәннәр, табын корганнар... Бүгенге көндә бу келәү текстларының кыйпылчыкларын гына ишетергә мөмкин, йола тәртибе дә төгәл генә сакланмаган...

«Келәү ае» дигән календарь ае да көзгә туры килә. «Үлдүкләр келәү» йоласының да шушы Келәү аена барып тоташуы бик мөмкин. Халык теленә «Келәү ае – көзнең таҗы», «Келәү ае – хисап ае» дигән гыйбарәләр, әйтемнәр кереп калган. Борынгы болгар-төркиләр кулланган Кояш-Ай календаре буенча да Келәү ае – унберенче ай – көз аена туры килә. Бу айда туган ир балаларга Келәш яисә Теләш дип исем кушканнар. «Татар теленең зур диалектологик сүзлеге»ндә Келәү аена «борынгы җирле календарь буенча елның алтынчы ае» дигән аңлатма бирелә. Шунда ук «Келәү ае көз башында була» дигән искәрмә дә бар.

Халык телендә «Келәү салу», «Келәү кую», «Келәү күтәрү» дигән гыйбарәләр булган. Алар шул исемдәге йолаларга нисбәтле каралалар. Келәү әйтеп, теләк теләп суга акча яисә башка мал салу – Келәү салу һәм шул су буендагы агач-куакларның ботакларына төрле төстәге чүпрәк-тасмалар бәйләп кую Келәү күтәрү дип йөртелгән. Колга башларына шундый ук чүпрәк-тасмалар, сөлгеләр элү гадәте дә булган.

Бу йола күпмедер дәрәҗәдә, теләкләр әйтеп, колга күтәреп, Сабантуйга бүләк җыеп йөрү йоласын да хәтерләтә.

Келәү кую йоласының да үзенчәлеге булган. Бик борынгы дәверләрдә бу йоланы башкарганда, бер капчыкка төрле хайван сөякләре тутырып, келәтләргә, сарай-абзарларга, чормаларга асып куйганнар. Еш кына капчыкка ризык әйберләре дә салып элгәннәр.

Бик борынгы мәҗүси келәү текстлары сакланмаган. Бигрәк тә ислам тәгълиматы татар кешесенең рухи дөньясын биләп алгач, мәрхүм нәсел бабалары рухына («үлекләр»гә) багышланган текстлар Кандалый чорында ук телдән төшеп калган. Келәүләр, бу беренчел мәгънәсен югалтып, көндәлек тормыш һәм табигать йолаларына сыенып яши башлаганнар.

Ә хәзер кайбер келәү текстлары белән танышыйк.

«ШУНЫ ДА ИСКӘРТЕРГӘ КИРӘК: БОРЫНГЫЛЫКТА БУЛГАН ТАБЫНУ, ЯЛВАРУ МӘГЪНӘСЕН ЮГАЛТЫП, СОҢГЫРАК ДӘВЕРЛӘРДӘ ТЕЛӘК ТЕЛӘҮ ҖЫРУЛАРЫНА ЯИСӘ БАЛАЛАР ТЕЛЕНДӘГЕ ТАКМАКЛАРГА ӘВЕРЕЛЕП ЯШӘГӘН«

## ҖИР ИЯЛӘРЕНӘ КЕЛӘҮ ӘЙТҮ

Бу келәүләр язгы, көзге кыр эшләренә керешер алдыннан Җир атасыннан, Җир анасыннан мул уңыш сорап, илгә иминлек, бөтенлек, бәрәкәт теләп әйтелә.

1
Җир атасы – Җирән сакал!
Җир анасы – Асыл бикә!
Түбәсенә туклыгың бир,
Тамырына ныклыгың бир,
Ил өстенә муллыгың бир,
Ил эчендә безгә дә бир!
Башлыйк теләкне,
Күтәрик беләкне,
Кояш, шаһит бул!

2
Җир, җир, көчем бир,
Ябага тайның көчен бир,
Алтын алма төсен бир,
Алты атым куәтен бир,
Алтмыш арба арыш бир,
Алтмыш арба бодай бир,
Алтмыш арба борай бир,
Алтмыш арба тары бир,
Бир, бир, барын бир!
Җир! Җир!

3
Бу елгы чәчүләр
Котлы, мөбарәк булсын,
Тормыш түгәрәк булсын,
Мал-туарлар да артсын,
Тай-колыннар да чапсын,
Игеннәребез уңсын,
Күкәй кебек тук булсын,
Йөзебез, күңелебез
Күкәй кебек ак булсын!

Чәчүгә, буразнага чыккан игенчеләр, шушы келәү сүзләрен тәкърарлап, чәчеләсе җир өстенә йомырка тәгәрәткәннәр. Кайчакта йомыркаларны иген бөртекләре белән бергә сипкәннәр. Бу йола тезләнеп башкарылган. Кара җиргә тезләнгән очракта гына Җир иясе мәрхәмәтле булачак, имеш.

4

Җир иясенә, Су иясенә мөрәҗәгать ителгән келәүләр бер үк вакытта сихердән, зәхмәттән, авырулардан саклану әфсеннәре, им-том текстлары буларак та актив файдаланганнар. Менә шуларның берничәсе:

Җир атасы – Җирән сакал,
Су атасы – Суган сакал,
Җир анасы – Сынлы бикә,
Җир кендеге – бер, су кендеге – бер,
Җирдән килсәң – җиргә кит,
Судан килсәң – суга кит,
Фазыл муллага таяк бирәм,
Садри муллага таяк бирәм,
Остабикәгә тарак бирәм,
Минем кулым түгел,
Имчеләр, картлар, карыйлар кулы,
Гайшә-Батман кулы
Тфү, тфү!..

«Зәхмәт кагылу»дан саклану өчен чыгарылган бу келәү-әфсен такмагын «җиргә салу» дип тә йөртәләр. Әлеге әфсен сүзләре авыру-зәхмәтләрне җиргә салырга булышалар, дип уйлаганнар.

5

(Егылып «җир зәхмәте» кагылган кешеләр тарафыннан әйтелә)

Җир атасы, Җир анасы,
Тоткан булсаң, җибәр!
Мин сиңа аш-су бирәм,
Син миңа йомшаклык бир!

## СУ ИЯЛӘРЕНӘ КЕЛӘҮ ӘЙТҮ

(Келәү текстыннан төшеп калган бу өзекне су тотудан саклану әфсене итеп тә кулланганнар)

Су анасы – Сылу сакал,
Җир анасы – Җирән сакал,
Күк анасы – Көрән сакал,
Мине ашама, мине эчмә,
Шушыны аша, шушыны эч,
Миннән көткәнең шул булсын,
Име-томы шушы икән,
Табылмыйча тора икән...

Шушы сүзләрдән соң суга ни дә булса салалар. Күпчелек очракта чәч бөртеге, киемнән суырып алынган җеп, тәңкәләр, энә-җеп, асыл, матур ташлар кулланганнар. Мондый «корбан»нардан соң су кешене алмый, имеш.

## УТ ИЯЛӘРЕНӘ КЕЛӘҮ ӘЙТҮ

(Уттан саклану әфсене буларак та кулланылган)

1

Ут атасы күк була,
Ут анасы сары була,
Утның кызы кызыл була,
Кызына калгач кызу була.
Ут, уйнама, уйнама!
Уйнамаек, көлмәек,
Бергә гомер итәек!..

Әлеге келәү-әфсенне әйтеп, ут чыккан җирдән өч тапкыр әйләнеп уза торган булганнар. Шулай, янәсе, ут сүнәргә тиеш.

2

Әй Ут-ана, Ут-ана,
Шушы булсын теләгем:
Йөрмә монда, ерак кит,
Менә сиңа бүләгем!
Өф-өф!.. У-у-ш-ш...

Бу келәү әфсенен әйткәннән соң, утка ни дә булса ташларга кирәк. Гадәттә, ул күлмәк (кеше сынына ишарәле) була. Кайчакта тимер әйбер ташлыйлар. Янәсе, тимергә «теше» үтмәгәч, Ут-ана, көчсезлеген танып, кире китә...

# «КАУРЫЙ БӘЙРӘМЕ» фольклор күренеше

**(«ХӘЗИНӘ» ФОЛЬКЛОР КОЛЛЕКТИВЫ МИСАЛЫНДА)**

*Ләйлә ХӘКИМОВА,*
*Арча районы Мәдәният йорты*
*сәнгать җитәкчесе*





КАТНАШАЛАР:
Хуҗабикә: Гүзәл Нигъмәтҗанова
Күрше: Зөлфия Яббарова
Кызлар: Фәрдия Дерин, Адилә Нотфуллина, Ләйлә Хәкимова
Егетләр: Инсаф Мөхәммәтгалиев, Дилүс Сәләхов, Илназ Абзалов, Вагыйз Әһлиуллин, Динар Бариев.

*(Йортта хуҗабикә чәй табыны әзерләп йөри.)*

**Зөлфия:**
Кулларымда ап-ак каурый,
Карасы булырмы икән?
Күрше өмәгә чакырса,
Барасы булырмы икән?
Исәнмесез-саумысез,
Әй, хуҗалар, кайда сез?
Өмәчеләр килеп җитте,
Нигә каршы алмыйсыз?

**Гүзәл:**
Күрми дә торам, әйдә, рәхим ит, түрдән уз, күрше! Менә, өмә хөрмәтенә чәй табыны әзерләп йөри идем.

**Зөлфия:**
Эш эшләми торып нинди чәй эчү ди ул? Башта эшне бетерик, күрше. Өмәче кызлар

килеп җиткәнче эшне башлап куя торыйк. Башлаган эш, беткән эш. Аннан соң, яшьләр безнең кебек оста итеп, җитез генә каз каурые сыдыра белмәсләр.

*(Кызлар керә.)*

**Ләйлә:**
Карагыз әле сез боларны, нәрсә дип сөйләнеп торалар. Ишетәсезме кызлар? Исәнмесез, апалар! Безне дә каурый сыдырырга өйрәтәсезме?

**Фәрдия:**
Әйе шул, без башкара алмаслык эш булмас. Рәтен белеп алсак, туктата да алмассыз әле.

**Зөлфия:**
Ышанабыз, ышанабыз. Баскан җирдән ут чыгара торган чагыгыз шул.

**Гүзәл:**
Ягез-ягез, килегез әле монда, кызлар. Менә, көз көне бергәләп суйган казларның каурыйлары монда. Күрдегезме? (Каурыйларны күрсәтә). Каурый өмәсе – халкыбызның бик борынгыдан килгән милли йоласы. Электән үк, кышкы озын кичләрдә хатын-кызлар, күрше-күлән һәм туганнар белән җыелышып каурый сыдырганнар. Каурый мамыгы мендәрләрне тагын да ныграк кабартып җибәрә. Казның бер әйберсе дә әрәмшәрәм ителми: каурый мамыклары мендәр, урындык киезләре эчлегенә тутырырга ярый, очында мамыгы калганыннан камыр ризыклары майлау өчен май канатлары, безнеңчә, дөргәчләр үрәләр.

**Адилә:**
Элек «Каурый өмәләре» бик күңелле үткән. Анда җыр-такмаклар яңгыраган, уен-көлке, биюләр дә булган. Җилкәнчек егетләр дә килгән.

*(Кызлар көлешәләр.)*

**Зөлфия:**
Каурый сыдыруның үз хикмәте бар, нечкәлекләрен белеп эш итәргә кирәк, кызлар. Менә хәзер ничек эшләргә кирәген күрсәтеп узам. Каурыйны алабыз, йомшак башыннан тотабыз һәм әкренләп мамыкны тартып төшерәбез. Әйдәгез, бергәләп эшләп карыйк.

*(Берничә каурыйны сыдырып күрсәтә. Кызларга булышып, өйрәтеп йөри.)*

**Зөлфия:**
Бу кадәр каурыйларны үзебез генә ничек сыдырып бетерербез дип бик борчылган идек, мондый булышчылар булганда башкарып чыгабыз. Яхшылап эшләгез кызлар, егетләр эшкә уңган, тырыш кызларны өмәләрдә күзлиләр дә инде. Аллаһы насыйп итсә, өмәдән парлашып та кайтырсыз әле.

**Фәрдия:**
Кызлар, карагыз әле, ә бу мамыклардан ясалган мендәрләр кемгә була?

**Ләйлә:**
Кемгә? Кемгә? Миңа булачак, менә күрерсез. Түбән Оч Илназ бу кыштан калмыйм, өйләнәм диде.

**Фәрдия-Адилә:**
Ничек сиңа?

**Гүзәл:**
Туктагыз, тукта. Сеңлем, син яшь әле, сабыр итеп тор. Өлгерерсең. Монда әле Фәрдия апаең бар. Киләсе елга укуын тәмамлый. Очрашып йөргән егете дә бар. Бәлки, тиздән шаулатып туй да ясап куярбыз. Заманасы башка булса да, бирнә, пар мендәрләр белән килен төшерү йоласы әле дә бар.

**Ләйлә:**
Ярый инде, мин бит шаяртып, үртәп кенә әйтәм.

**Зөлфия:**
Без дә пар мендәрләр белән килен булып төшкән идек. Аллаһка шөкер, парлы булып гомер итәбез. Әле әтисе, егетләрне өмәгә чакырам, дип киткән иде. Әнә, тавышлары да ишетелә, килеп тә җиттеләр.

*(Егетләр тавышы ишетелә. Такмаклар әйтешеп җырлыйлар.)*

**Егетләр:**
Сандугачның балалары
Талга кунганнар икән.
Кызларыгыз тырышып эшли,
Бигрәк уңганнар икән.
Тәрәзәдән карыйсыз,
Карап кемне таныйсыз?
Карап тилмереп торганчы
Ник чакырып алмыйсыз?

**Кызлар:**
Күңелле каурый бәйрәме,
Бездә бүген зур бәйрәм.
Җырлый-җырлый, бии-бии
Уйнарбыз әйлән-бәйлән.
Масаеп йөрмәгез әле,
Уйлагыз керү ягын.
Ишекне бикләп куярбыз,
Шундый сүз булса тагын.

**Егетләр:**
Ишекне ача белмибез,
Торабыз өшеп, катып.
Ишегегезне күтәреп,
Китәрбез әле кайтып.

**Кызлар:**
Бусага хакын җәлләмә,
Сезгә киңәш шул булыр.

**Егетләр:**
Бусага хакы капчыкта,
Кердек ишек ачыкка.
Егетләрнең күчтәнәче
Сезгә булыр тансыкка.

**Адилә:**
Егетләр, сезгә ни кирәк?

**Инсаф:**
Пешкән, симез кыз кирәк!
Юкла, симез каз кирәк!

**Дилүс:**
Тагын матур кыз кирәк.

**Фәрдия:**
Каз казанга төшмәгән,
Егет үзе пешмәгән!

*(Кызлар көлешәләр.)*

**Алмаз:**
Җитәр инде пешердегез,
Шыбыр тиргә төшердегез.

**Ләйлә:**
Кызлар, әйдәгез егетләргә канат сатыйк әле, йоласы шундый бит.

**Барысы бергә:**
Әйдәгез, әйдә.

**Зөлфия:**
Канат сатабыз канат,
Яхшысын сайла карап.
Егет булсаң канат ал,
Бер алтын чыгарып сал.

**Илназ:**
Кыйммәт икән, бер алтын...
Канатлар сездә калсын!

**Кызлар барысы да бергә:**
Саран икәнсең, Илназ.

**Фәрдия:**
Егет саран булмасын,
Акча җәлләп тормасын.
Кем чын егет – шул алсын!

**Инсаф:**
Ягез, бирегез әле кызлар. Үзем алам.
(Акча салынган төенчек бирә.)

**Ләйлә:**
Җыр-биюсез бер бәйрәм дә
Узмый – шуны белегез,
Каурый өмәсендә бүген
Рәхәтләнеп биибез.
Егетләр-кызлар, алыш-бирешне котлап, бер уйнап алыйк әле.

*(Җырлы-биюле «Так калыш», «Ачык авыз», «Канат салыш» уеннары уйнала.)*

**Гүзәл:**
Эшнең кызу чагында килдегез сез, егетләр. Кызлар, җырлап-биеп кенә эш бармый. Мендәрләргә әзер мамыкларны тутырырга кирәк, аның да үз тәртибе бар. Менә карагыз әле, әниебез чиккән мендәр тышлары бу (мендәр тышларын күрсәтә). Әлеге мендәр тышларын ике яктан тотып торырга парлы егет белән кыз кирәк.

**Ләйлә:**
Инсаф белән Фәрдия тотсын.

**Илназ:**
Ләйлә, әллә үзебез тотыйкмы?

**Ләйлә:**
Апайдан узып булмас шул, сабыр итәсе булыр.

**Фәрдия:**
Дөрес, дөрес. Без тотабыз.

*(Яшьләр ике яктан мендәр тышын тоталар, Вагыйз белән Гүзәл теләкләр теләп мендәргә мамык тутыралар.)*



**Гүзәл:**
Мамыклар белән тулган
Мендәрләр йомшак булсын.
Парлы мендәр өсләрендә
Гашыйклар гына кунсын.

**Вагыйз:**
Икегезгә ике сүрү,
Ягез әле, тотыгыз,
Йомшак булсын мендәрегез,
Мамыкны күп салырбыз.

**Гүзәл:**
Мендәр ясыйм, мендәрләрем
Йомшак булсалар иде.
Халкым гореф-гадәтләре
Мәңге сакланса иде!

**Зөлфия:**
Булды бу. Мамык чыкмасын өчен сүрү кырыен тегеп куярга кирәк, аны кичке өмәдә кызларыбыз жырлый-жырлый тегәрләр.

**Гүзәл:**
Тырышып эшләсәң – тәмләп ашарсың, диләр. Бәйрәмебезне чәй өстәле янында дәвам итәбез. Барыгызны да коймак белән чәй эчәргә чакырам. Рәхим итегез! Әйдәгез, әйдә, түрдән узыгыз.

Фоторәсемнәр авторның шәхси архивыннан

*Земфира МӨХӘММӘТШИНА,*
*Апас халык театры режиссеры*

# ТЕАТР – ҮЗЕ БЕР СИХРИ ДӨНЬЯ

АПАСТА БЕРЕНЧЕ СПЕКТАКЛЬ 1921 ЕЛНЫҢ КЫШЫНДА, КАЙЧАНДЫР КАДЫЙР БАЙНЫҢ СӘҮДӘ КИБЕТЕ БИНАСЫНДА КУЕЛА. АНЫ АПАС УКЫТУЧЫЛАРЫ ӘЗЕРЛИ. УЛ Г. КАМАЛНЫҢ «БЕРЕНЧЕ ТЕАТР» ӘСӘРЕ БУЛА. БҮЛМӘЛӘРНЕҢ КЫСАН БУЛУЫ ДА, СӘХНӘГӘ КИРӘКЛЕ ДЕКОРАЦИЯЛӘРНЕҢ, ҮЗЕШЧӘН АРТИСТЛАРГА КИЕМНӘР БУЛМАВЫ ДА КОМАЧАУЛАМЫЙ. УКЫТУЧЫЛАР КИРӘКЛЕ ӘЙБЕРЛӘРНЕ ҮЗ ӨЙЛӘРЕННӘН АЛЫП КИЛӘЛӘР, ҖИТМӘГӘННӘРЕН ТАБУНЫ УКУЧЫЛАРЫНА ЙӨКЛИЛӘР. ДИНЧЕЛӘР ЗӘҺӘРЛӘНЕП, ҺӘР ЯҢАЛЫККА КАРШЫ ЭШ ЙӨРТӘ ТОРГАН ЧОР БУЛА УЛ.



Карарга халык килмәс дип, балаларга иптәшләрен җыеп килү дә кушыла. Әмма бина тамашачы белән тула. Апаска терәлеп торган Әнәле авылыннан да спектакль карарга киләләр. Дин әһелләре «шайтан уены» оештыручыларны һәм аны карарга килгән халыкны «җир йотачак» дип куркыта. Дингә ышанучылар куркуга кала. Ләкин һәвәскәр сәнгать активистлары моңа җавап итеп, яңа спектакль әзерлиләр. Бу юлы сәхнәгә Апас яшьләре һәм өлкән буын кешеләре дә тартыла.

Һәвәскәрлек эше дәһшәтле чорда – Бөек Ватан сугышы елларында да тукталмый. Үзешчәннәр театр тылсымы белән кешеләр күңеленә рухландыргыч тойгылар, җиңүгә ныклы ышаныч хисе өстәп яшиләр.

1971 елда Апас театр коллективына «халык театры» исеме бирелә. Ул чактагы мәдәният бүлеге җитәкчесе, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре Фәрит Кәлимуллин коллективка исем бирдерү өчен барлык көчен куя. Апас халык театры үзенең беренче спектакле итеп, Т. Миңнуллинның «Күрше кызы» пьесасын сәхнәләштерә. Аны, Апас якларына эшкә кайткан, Актаныш кызы Галия Анамова әзерли. Аннан соң режиссёр Кәрим Насыйбуллин тарафыннан Әсхәт Мирзаһитовның «Куендагы елан», Миргалим Харисовның «Туачак сабыйлар хакына», Юныс Әминовның «Өти балак Гөлүзә», Абдулла Әхмәтнең «Үги кыз» әсәрләре халыкка куела.

1975 елда Апас мәдәният йортына эшкә Казан сәнгать училищесын тәмамлаган яшь белгеч, рәссам-декоратор Фирдәвес Абдуллина кайта. Спектакльләрнең сәхнә бизәлешен бермә-бер уңышлы һәм зәвыклы итү мөмкинлеге туа. 1977 елда Апас халык театрында, режиссёр булып, Казан дәүләт мәдәният институтының театр-режиссерлык бүлеген тәмамлаган яшь белгеч Миләүшә Алиуллина эшли башлый. Икесе – Миләүшә Алиуллина белән Фирдәвес Абдуллина 40 елга якын гомерләрен халык театрына багышлыйлар. Ул елларда Апас халык театры районкүләм, республикакүләм, хәтта россиякүләм оештырылган бәйгеләрдә катнашып, лауреат буларак таныла.

Соңрак Миләүшә Алиуллинага алмашка, режиссер булып, Гөлия Сәләхетдинова, Айгөл Хәмидуллина килә. 2017 елдан алып бүгенге көнгәчә Апас халык театрын Земфира Мөхәммәтшина җитәкли. Халык театры коллективында район үзәгендә генә түгел, ә авылларда яшәүче, сабый баладан алып сиксән ягына чыккан артистлар да бар.

2021 елның кышында Апас халык театры үзенең 50 еллык юбилеен билгеләп үтә.

Узган 2023 елда Апас халык театры Ш. Зиннуров исемендәге төбәкара «Идел-йорт» халык театрлары фестивалендә Әмир Камалиевның «Борын-борын заманда...» исемле музыкаль спектакле белән катнашып, беренче дәрәҗә дипломга һәм беренче урынга ия була. Берничә ел рәттән дипломант булып килсәләр дә, бу Апас халык театры тарихында тәүге җиңү – иң зур уңышларының берсе.

Бүген без сезне 34 ел гомерен Апас халык театрына багышлаган Ләйсән Әкбәрова белән таныштырабыз. Сәнгать дөньясына ничек килеп керүе турында менә ниләр сөйләде ул.

– 1990-1991 еллар. 8 сыйныфта укып йөргән чагым. Ул чактагы режиссер Миләүшә апа Алиуллина «Хуш, Назлыгөл» спектаклендә уйнарга чакырды. Аңа кадәр мин, Миләүшә апа җитәкчелегендәге «Мушкетерлар» балалар театр студиясенә йөргән идем. Бүгенгедәй хәтеремдә, шәфкать туташы роле иде ул. Без әлеге



2017 ЕЛДАН АЛЫП БҮГЕНГЕ КӨНГӘЧӘ АПАС ХАЛЫК ТЕАТРЫН ЗЕМФИРА МӨХӘММӘТШИНА ҖИТӘКЛИ

спектакльне Г. Камал театрының зур залында да уйнап кайттык (халык театрлары арасында беренче урынга лаек булдык). Спектакль ахырында, Татарстанның халык артисты Гөлсем Исәнгулова сәхнәгә менеп үземне мактаган иде шунда, чакыру билеты язып биргән иде. Мин аны кадерле истәлек итеп хәзер дә саклыйм.

Кечкенәдән радио аша спектакльләр тыңларга яратам. Үзем берәр эш эшлим, уйларым радиода яңгыраган спектакльгә кереп чума...

Шунысы кызганыч, элегрәк уйнаган рольләремдә фотога төшелмәгән. Зурлар труппасы белән авылдан авылга гастрольгә чыгып китүләр ошый иде миңа. Шул чакларда дәресләрне дә карап өлгергәнмен, гаиләдә өлкән бала буларак, әти-әни кушкан эшләрне дә үтәгәнмен.

Әле дә хәтеремдә, май ае иде. Миңа Миләүшә апа 200 сум хезмәт хакы бирде. Шул акчага үземә коңгырт төстәге, яз-көз кия торган, 120 сумлык сапоги сатып алдым. Шатлыгым эчемә сыймый. Озак яратып кидем мин ул сапогины. Җае чыккан саен һәр кешегә «үзем эшләп алдым» дип сөйли идем.

Гастрольләрдә йөргәндә кызык хәлләр дә булгалый иде. Г. Камал театрына баргач буфетына ашарга кердек. Миңа да йомырка тәбәсе алганнар. Янында чәнечкесе дә бар. Авыл баласы чәнечке белән ашый беләмени ул?! Чәнечке белән орынуым булды, чиле-пешле сарысы агып китмәсенме?

Шулай бервакыт сәхнәдә уйнаганда Миләүшә апаның туфлие аягыннан салынып очып китте. Мин сәхнә артында, нәрсә була инде дип, борчылып торам. Миләүшә апа, үзен шулай тиеш кебек тотты, барып алды да, киеп тә куйды. И куанганнарым шунда...

Авылларга чыкканда клуб автобусы белән йөрибез. Шоферыбыз Әнсар абый. Ул үзенә бертөрле кызык кеше иде. Берсендә Кзыл-Тау авылына спектакль куярга бардык. Бер тар гына агач күпердән чыгарга кирәк. Кайтканда Әнсар абый: «Мин моннан рульне аяк белән дә йөртеп чыгам», – димәсенме... Миләүшә апа гаугаланып: «Җүләрләнмә инде, алай булгач төшер безне, арабыздагы баланы әти-әнисенә исән-сау алып кайтып тапшырасым бар», – дип ялвара башлады. «Утырыгыз тик кенә, мин Әнсар ич!» – дип кычкырды да, тәки алып чыкты бит шулай аяклары белән рульне йөртеп. Миләүшә апа елый, мин көләм, чөнки кызык, курку хисе юк чак.

Якташыбыз, драматург Хәбир Ибраһимга (Ахир) рәхмәтле мин. Аның «Хатыным-алтыным» спектаклендә Өмәмә ролен башкардым. Хәбир абый шул әсәре буенча «Ялгыз тәкърлек»




ЯКТАШЫБЫЗ, ДРАМАТУРГ ХӘБИР ИБРАҺИМГА (АХИР) РӘХМӘТЛЕ МИН.
АНЫҢ «ХАТЫНЫМ-АЛТЫНЫМ» СПЕКТАКЛЕНДӘ ӨМӘМӘ РОЛЕН БАШКАРДЫМ



**Ләйсән Әкбәрова кызы Риана белән**

исемле кинофильм да төшерде. Фильмда массовкада гына катнашсам, спектакльдә Өмәмә ролен тулысы белән уйнадым. Легендар Фирдәвес Әхтәмова белән бергә уйнау, чәкердәшеп чәй эчә-эчә сөйләшеп утыру – миндә бер горурлык хисе тудырды!

Башкарган рольләрем барысы да күңелемә якын. 15 яшьлек кызлардан 85 яшьлек карчыкка хәтле уйнадым. Сәмига Сәубанова әсәре буенча куелган «Күпер» спектаклендә Гөлбану карчык ролен уйнаганда, Миләүшә апа беренче мәртәбә грим салгач, көзгедән үземне күреп, танымадым: бик картайган, куркыныч кыяфәттә идем. Кем генә булып уйнасам да, тамашачының җылылыгын тойгач, мактау сүзләре ишеткәч, үз-үземә ышанычым арта барды.

Еллар уза торды... Апас халык театрында бер-бер артлы режиссерлар да алышынды. Бүгенге көндәге халык театрын җитәкләгән яшь, талантлы режиссерыбыз Земфира Мөхәммәтшинага да мин рәхмәтле. Туры килгән рольләр булса, чакырып ала. Гаиләбез белән Зөлфәт Хәкимнең «Шайтан куентыгы» спектаклендә уйнадык.



Тормыш иптәшем Ринат та сәнгать кешесе – ул Буа дәүләт драма театры артисты. Безне театрга булган мәхәббәт кавыштырды. Раил Садриев Буа дәүләт драма театрын җитәкли башлагач, алар – Апаска, без Буага барып куя идек спектакльләрне. Булачак ирем белән шулай танышып киттек. 2013 елда кызыбыз

БАШКАРГАН РОЛЬЛӘРЕМ БАРЫСЫ ДА КҮҢЕЛЕМӘ ЯКЫН. 15 ЯШЬЛЕК КЫЗЛАРДАН 85 ЯШЬЛЕК КАРЧЫККА ХӘТЛЕ УЙНАДЫМ






ТОРМЫШ ИПТӘШЕМ РИНАТ ТА СӘНГАТЬ КЕШЕСЕ – УЛ БУА ДӘҮЛӘТ ДРАМА ТЕАТРЫ АРТИСТЫ. БЕЗНЕ ТЕАТРГА БУЛГАН МӘХӘББӘТ КАВЫШТЫРДЫ




Риана тугач, гаиләне туендыру өчен, Ринат театрдан китәргә мәҗбүр булды. Оренбургтан килгән бер артист дусты: «Мин дә киткән идем, кире әйләнеп кайттым, сәхнә чире – гомерлек чир», – дигән иде. Шулай булды да, Ринат 5 елдан соң Буа театрына әйләнеп кайтты, сәхнә барыбер кире үзенә тартты аны...

Кызыбыз Риана да Апас халык театрында үзенең тәүге адымнарын ясады. Әниле-кызлы булып, Шәриф Хөсәеновның «Әни килде» спектаклендә уйнадык. Мин Расиха булсам, кызым Рәйхан ролен башкарды. Рианага кайнап торган сәхнә тормышы бик ошый.

Театр – үзе бер сихри дөнья. Без анда бер гаилә кебек: өлкәне дә, яше дә, кечесе дә бертугандай иҗат итәбез. Шул мохиттә кайнау, яңадан-яңа рольләр башкару – безнең театр гаиләсе өчен зур бәхет!

Фоторәсемнәр авторның шәхси архивыннан

*Рәзилә МӨХӘММӘТРӘХИМОВА,*
*Балык Бистәсе, Яңа Арыш авылы китапханәсе мөдире*

# Балык Бистәсендә – «Бистә шәле» бәйрәме

Балык Бистәсе районында быел «Бистә шәле» республикакүләм хатын-кызлар кәсебе фестивале 2нче тапкыр уздырылды. Традициягә әйләнеп килә торган әлеге чара Гаилә елы кысаларында оештырылды. Беренчесе аның 2023 елда булган иде.

Фестивальне карарга бик күп кунаклар – Татарстанның һәм Россиянең халык артисты, Г. Тукай һәм М. Җәлил исемендәге республика премияләре лауреатлары иясе, тормыш иптәше Раушания ханым белән якташыбыз Равил Шәрәфиев, Татарстан Республикасының мәдәният өлкәсендә инновацияләр һәм традицияләр саклау ресурс үзәгеннән проект эшчәнлеге һәм мәдәни инициативаларга ярдәм итү секторы мөдире Гүзәл Фәезова, фестиваль һәм конкурс программалары бүлеге мөдире Нияз Кәримуллин, шулай ук якташыбыз Казан кооператив институтының




СПАС



Дәрдемәнд исемендәге Татар мәдәнияте үзәге җитәкчесе Флюра Абдуллина, Татарстанның халык артистлары, Кәрим Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театрының йөзек кашлары – Сәкинә һәм Рамил Минхановлар, «Акчарлак» нәшрият йорты директоры, продюсер, режиссер Рузилә Сафина, «Матбугат.ру» ресурсы җитәкчесе Данил Сәфәров, «Интертат» журналисты Юлай Низаев һәм башкалар кайткан иде. Кунакларны театральләштерелгән тамаша белән бию коллективлары каршы алды. Фестивальдә катнашучыларны Балык Бистәсе районы башлыгы Радик Ислямов сәламләде.

Районыбызның Мәдәният бүлеге җитәкчесе Лилия Кәримуллина да сүз алды.

– Күгәрчен авылында борынгыдан шәл бәйләү осталары күп булган. Бүгенге көндә алар районыбызда да шактый. Ниятебез – шул кәсепчелекне, матур традицияне саклап калу. Яшьләр, киләсе буыннар да бу шөгыльне күреп, белеп үссен иде. Алдагы елда бу фестивальне төбәкара дәрәҗәдә үткәрергә уйлыйбыз. Әлеге күркәм чара безнең гореф-гадәтләребезне данлый, – диде ул.

Фестивальдә быел Әтнә, Әлки, Буа, Алексеевск, Ютазы, Кукмара, Норлат, Арча, Мөслим, Саба районнарыннан килгән ансамбльләр, иҗат төркемнәре катнашты. Балык Бистәсе районы Мәдәният йорты каршында эшләп килүче, Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре Фирдания Бәдретдинова җитәкчелегендәге «Өмет» халык фольклор ансамбле дә фестиваль кунакларын матур җырлары белән сөендерде. Районыбыздагы Фәтхерахман Әхмәдиев исемендәге балалар сәнгать мәктәбенең «Рәйхан» курайчылар ансамбле чыгышы да, Кызыл Йолдыз лесхозы клубы каршындагы «Чулпы» керәшен халык фольклор ансамбле чыгышларын да тамашачылар алкышларга күмде. Лилия Җиһаншина җитәкчелегендәге «Зәкәрия» фольклор төркеме – бәйрәмебезнең махсус кунагы булды. Килгән кунаклар аларны бик җылы





кабул итте, кушылып җырлап, рәхәтләнеп күңел ачтылар.

Фестивальдә йоннан һәм аксессуарлардан эшләнгән әйберләр коллекцияләре дефилесы тәкъдим ителде. Мамык йоннан бәйләнгән күз явын алырлык косынкалар, шәлләр, бияләйләр, баш киемнәре, шарфлар беркемне дә битараф калдырмады. Чара барышында «Иң тиз йомгак чорнаучы» бәйгесе узды. Әлеге бәйгедә I урынны – Түбән Тегермәнлек авылыннан Рәшидә Мөбәрәкшина, II урынны – Юлсубинодан Сания Мөхәммәтшина, III урынны – Котлы Бөкәштән Асия Бариева яулады, ә Гран-прига Ямаш авылыннан Исламия Сафина лаек булды.

«Иң тиз шәл бәйләүче» бәйгесендә иң оста, иң уңган, иң тиз бәйләүче ханымнар ут уйнатты. Бәйге нәтиҗәләре буенча, Юлсубино авылыннан Сания Мөхәммәтшинага – I урын, Күгәрчен авылыннан Гүзәлия Мөхәммәтҗановага – II урын, Гүзәлия Хәмәтхановага – III урын, Сәрия Кәримуллинага Гран-при бирелде.

«Иң креатив шәл» бәйгесендә җиңүчеләр булып, Балык Бистәсеннән Фирдәвес Кадыйрова (I урын), Күгәрчен авылыннан Гөлфирә Кәлиева (II урын), Бирдебәк авылыннан Евдокия Толстова (III урын) танылды, Балык Бистәсеннән Раилә Шәрипова Гран-при иясе булды.

Бәйгеләрдә катнашып, җиңү яулаган барлык катнашучыларга Дипломнар һәм истәлекле бүләкләр тапшырылды.

Чара дәвамында шәлләрдән, халык кәсепчелегеннән торган, «Бистә кабартмасы» дип аталган татар милли ризыклары күргәзмәләре эшләде. Районда гамәлдә булган «Капка төбендә», «Эх, гармуннар уйный белсәм...», «СПАС», «Җәйге алан» проектлары кысаларында Яңа Арыш авылыннан килгән «Мирас» ансамбле кызлары, оста гармунчылар һәм районның фольклор коллективлары кунаклар игътибарына милли җырлар, уеннар тәкъдим иттеләр.

Чара ахырындагы мизгелләрдә кәҗә мамыгыннан бәйләнгән күп төрле косынкалар, «3D-шәл» тәкъдим ителде. «Бистә шәле» республика хатын-кызлар кәсебе фестивале быелгы елның иң күркәм вакыйгасы булып истә калды.

Ирина Зимнякова һәм Гүзәл Хәбибуллина фоторәсемнәре

# *Бай тарихлы Байсар*

Уфа-Казан юлы буйлап барганда, Татарстан чигендә, гүзәл Сөн елгасы буенда Иске Байсар авылы кала. Байсар авылы 1713 елда оешкан. Әмма авылдашыбыз, язучы, тарихчы, галим, Г. Исхакый, Г. Тукай, И. Юзеев премияләре премиясе лауреаты, Татарстан Республикасының халык язучысы Вахит Имамов фикере буенча, авылга иртәрәк, унҗиденче йөздә үк нигез салынган булуы да мөмкин. «Байсар» сүзе кеше исеменнән алынган, рәсми кәгазьләрдә русча «Байсарино» дип йөртелгән.

Тарих битләренә күз салсак, Иске Байсар авылы Уфа губернасы Минзәлә өязенең Байсар волостена караган. Бу җирлектән Пугачев явы узган, Әби-патша юлы үткән, шулай ук биредә тирә-якка данлыклы «Байсар базары» булган. Земская больницасы, МТСы, сөт һәм май, кирпеч заводлары, мәдрәсәләре, мәктәбе, дүрт мәчете – Җәмигъ мәчете, Ак мәчет, Сары мәчет, Яшел мәчетләре булган 4 мәхәлләле авылда халыкка Әндрәй бай кибетләре дә хезмәт күрсәткән. Әндрәй бай үзе Минзәлә шәһәрендә яшәгән. Байсар авылында икешәр катлы өч кибет торткан. Бик юмарт булган Әндрәй бай, бәйрәмнәрдә авыл халкына бүләкләр өләшкән. Бүгенге көндәге, «Монда сиңа Әндрәй казнасы юк», дигән әйтем дә шуннан калган диләр.

2018 елдан бирле, кабаттан яңартылып, Байсарда «Базар көне» үткәрелә. Шул көнне



**«Авылым тарихы» музее**

тирә-як авыллардан, районнардан гына түгел, күрше Башкортстан республикасыннан, Удмуртиядән дә һөнәрчеләр килә. Алар халыкка мастер-класслар күрсәтә. «Базар көне»ндә авыл халкы сатуга чәй үләннәре, бал, минек, сөт ризыклары, яшелчә, җиләк-җимеш кебек, үзе житештергән продукцияне, һөнәрчеләр







**Әнвәретдин Вәлиев**

тимер эшләнмәләре, төрле кул эшләре, чигелгән картиналар, ясалган гөлләр алып чыга. Ул көнне авыл үзешчәннәре, район мәдәният хезмәткәрләре халыкка бәйрәм концерты күрсәтә.

Байсар авылыннан бик күп күренекле шәхесләр чыккан: дәүләт эшлеклесе, Татарстан Халык Комиссарлары Советы рәисе – Шәйгардан Шәймәрдәнов, Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре, «Сөембикә» журналы журналисты Эльмира Закирова, Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре, Татарстан журналистлар берлеге, СССР



журналистлар һәм язучылар берлекләре әгъзасы, журналистларның Хөсәен Ямашев исемендәге премиясе лауреаты Индус Сирматов, Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе, доцент, якташыбыз Әлфия Авзалованың беренче гармунчысы, баянда өйрәнү буенча дәреслекләр авторы, Казан дәүләт педагогия институтының музыкаль тәрбия нигезләре кафедрасы өлкән укытучысы Фәнис Гыйльметдинов, Актаныш районының «Алтын йөрәкле кеше»се исеменә лаек булган, 2015 елдан башлап, Джип-Спринт автоузышларын оештырып, Байсар авылы данын Бөтенроссия дәрәҗәсендә таныткан, 2023 елда Россиянең спорт мастеры исеменә лаек булган авылдашыбыз Рәдис Хашимов, хоккейчы кызыбыз, Россиянең спорт мастеры Лиана Ганеева һәм башкалар.

Иске Байсар авылында бүгенге көндә «Авылым тарихы» музее эшләп килә. Аны Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре, 45 ел гомерен мәдәниятка багышлаган моңлы тавышлы, җор телле нәфис сүз остасы Әнвәретдин Вәлиев оештыра.

**Фәнзилә ХӘЙРИЕВА,
Актаныш, Иске Байсар
Мәдәният йорты җитәкчесе**




# ТАПКЫР КЫЗ

*(Әкият)*

Бер авылда бер карт яшәгән, ди. Унбиш яшьләрендәге бер кызы гына булган моның. Бабай көн дә урманнан бер йөк коры утын алып кайта икән дә базарга илтеп сата икән, шуның белән көн күреп тора икән, ди.

Шулай көннәрдән бер көнне бабай, бер йөк утын төяп, шәһәргә бара. Утын базарына барып керсә, каршысына бер бай килеп чыга моның.

– Бабай, утыныңны сатасыңмы? – ди бай.

Бабай әйтә:

– Сатам, – ди.

– Ни хак?

– Биш тәңкә.

– Тулаем сатасыңмы?

Бабай әйтә:

– Тулаем, – ди.

Бай: «Тулаем сатасыңмы?» – дип, өч рәт әйттерә дә:

– Әйдә, җитәклә үгезеңне, акча өйдә, – ди.

Китәләр болар. Байның ишегалдына барып керәләр. Ишегалдына кергәч, хуҗа капканы ябып куя. Аннары өйгә кереп, биш сум акча алып чыга да бабайга бирә.

– Бабай, эшең бетте, әйдә, йөгер, – ди.

Шулай дип бабайны кече капкадан җитәкләп чыгармакчы була.

Бабай әйтә:

– Утынны бушатыйм, үгезне алып китим, – ди.

Бай әйтә:

– Үгез белән арба синеке түгел, мин тулаем алдым, – ди.

Бабай әйтә:

– Мин риза түгел, әйдә казыйга, – ди.

Китәләр болар казыйга.

Барып кергәч, казый сорый:

– Ни йомыш белән килдегез? – ди.

Бабай әйтә:

– Мин моңа утын саттым, үгез белән арбаны бирми, – ди.

Казый байга әйтә:

– Нигә бирмисең? – ди.

Бай әйтә:

– Тулаем алдым мин, шулай дип өч рәт әйттердем үзеннән, – ди.

Казый бабайга әйтә:

– Тулаем сатам дип, өч мәртәбә әйттеңмени? – ди.

– Әйттем шул, – ди бабай.

– Алай булгач, бабай, гаеп итмә, мин гадел хөкем итәм, утының, арбаң, үгезең байныкы була, – ди казый.

Бабай, биш тәңкәсен тотып, елый-елый кайтып китә.

Әтисенең елап кайтканын кыз тәрәзәдән күреп ала да:

– Әти, ни булды сиңа? – дип каршы чыга.

Өйгә керәләр болар. Кергәч, хәлне сораша. Бабай әйтә:

– Бер бай мине алдады, утыным, арбам, үгезем биш тәңкәгә китте, казый да аның сүзен дөресләде, – ди.

– Әти, кайгырма, – ди кыз, – безнең тагын бер үгез бар бит әле. Бүген утын төяп төш тә, иртәгесен мине алып барырсың, үзем сатулашырмын, син читтәрәк торырсың, – ди.

Бабай, үгезне җигеп, урманга менә дә коры утын төяп төшә.

Иртәгесен, кызны утыртып, базарга китә бу. Утын базарына кергәч, бабай читтәрәк йөри. Кыз янына теге бай килеп чыга.

– Кызым, утыныңны сатасыңмы? – ди.

– Сатам, хакы биш тәңкә, – ди кыз.

Теге әйтә:

– Тулаем сатасыңмы? – ди.

Кыз әйтә:

– Тулаем, тулаем, – ди.

Бай әйтә:

– Әйдә өйгә, акчаны өйдә бирермен, – ди.

Өенә китәләр, ишегалдына кергәч, бай капканы яба да, өйгә кереп, биш сум акча алып чыга.

Алып чыга да кызга:

– Мә! – дип, кулын суза.

Кыз тегенең кулыннан ныгытып тота да:

– Бу акчаны кулың белән бирдеңме? – ди.

Теге әйтә:

– Кулым белән, – ди.

– Кулың беләнме?

– Кулым белән.

Өч мәртәбә әйттерә кыз да. Шуннан соң бай кулын тартып алмакчы була, кыз җибәрми.

– Кулың минеке, риза булмасаң, әйдә казыйга, – ди.

Казыйга баралар болар җитәкләшеп. Казый болардан:

– Ни йомыш белән килдегез? – дип сорый.

Кыз әйтә:

– Утын саттым моңа тулаем, – ди. – «Бу акчаны кулың белән бирдеңме?» – дип әйткәч, «Кулым белән бирдем», – диде. Өч мәртәбә әйттердем. Шулай булгач, кул минеке булырга тиеш, казый әфәнде, – ди.

Казый байга әйтә:

– Кулым белән бирдем дип, өч мәртәбә әйттеңме? – ди.

– Әйттем, – ди бай.

– Алай булгач, кулың бу кызныкы, хәзер төбеннән кисәм дә кызга бирәм, кулыңны кызгансаң, мең тәңкә акча чыгарып сал, – ди казый.

Бай мең тәңкәне өстәлгә чыгарып сала, гарип каласы килми. Аннан соң әйтә:

– Бу акча янына тагын мең тәңкә салам, ялган сөйләп кем җиңәр, җиңгән кеше алыр, – ди.

Тагын мең тәңкә акча чыгарып сала да кызга әйтә бу:

– Әйдә, сөйлә, – ди.

Кыз моңа әйтә:

– Син сөйлә, – ди.

Бай:

– Син сөйлә, – ди.

Кыз әйтә:

– Алайса, тыңлагыз, сөйлим. Минем әти элек вакытта бик бай кеше булган. Бохара ягында сату итеп йөргән. Беркөнне әтинең атлары бер күпергә кергәч, бу бай үзенең кешеләре белән күпер астыннан чыккан да, атларны туктатып, әтинең малларын талаган, әтинең үзен, үтереп, суга ташлаган, – ди һәм сикереп тора да:

– Атамның хакын алам, – дип, байга ябыша.

Бай ни әйтергә белми, каушый. «Үтермәдем, бу кыз ялган сөйли» дисә – оттыра; «үтердем» дисә – гаепле була. Бай, ни әйтергә белмичә, түшенә суга да үзенә үзе ачуланып чыгып китә.

Казый ике мең тәңкәне җыеп ала да, ак яулыкка төйнәп, кыз кулына тоттыра. Аннары, яхшы ат җиктереп, рәхмәт тапкырлыгыңа дип, кызны авылына озата.

**Татар халык әкиятләре. –**
**Казан: Татарстан китап нәшрияты, 2021.**

# Таныш булыгыз: «АСЫЛЪЯР» МУЗЫКА, ҖЫР ҺӘМ БИЮ АНСАМБЛЕ

**УДМУРТИЯ РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ИЖЕВСК ШӘҺӘРЕНДӘГЕ «АСЫЛЪЯР» МУЗЫКА, ҖЫР ҺӘМ БИЮ АНСАМБЛЕ 2010 ЕЛДА ОЕШТЫРЫЛА. БҮГЕНГЕ КӨНДӘ АҢА 3 ЯШЬТӘН АЛЫП 18 ЯШЬКӘ КАДӘРГЕ 80 БАЛА ЙӨРИ. 2018 ЕЛДА АНСАМБЛЬГӘ «ҮРНӘК» ИСЕМЕ БИРЕЛЕП, УНИКАЛЬ КОЛЛЕКТИВЛАРНЫҢ БЕРСЕ БУЛЫП ТАНЫЛА. АНДАГЫ БАЛАЛАР ҖЫР, БИЮ ҺӘМ АКТЕРЛЫК КҮНЕКМӘЛӘРЕНӘ ИЯ БУЛГАН АРТИСТЛАР ГЫНА ТҮГЕЛ, ТӨРЛЕ МУЗЫКА КОРАЛЛАРЫНДА УЙНЫЙ БЕЛҮЧЕ ОСТАЛАР ДА.**




УЙНАГЫЗ, ГАРМУННАР!
ИГРАЙ, ГАРМОНЬ!






– Ансамбльнең репертуары күп төрле: болар – Удмуртиядә яшәүче татар, башкорт, керәшен халыкларының, нугайбәкләрнең гореф-гадәтләре («Нәүруз» бәйрәме, «Балалар уеннары», «Исем куштыру», «Солдатка озату», «Сабантуй мизгелләре», «Карга боткасы»), һәм шулай ук җырлар, биюләр, традицион уен коралларында (гөслә, думбыра, кубыз, дәф, курай, бәрмә кораллар) башкарылган төрле композицияләр, татар әкиятләре һәм риваятьләре («Шүрәле», «Ике кыз», «Миллләтебез хәзинәләре») буенча куелган музыкаль спектакльләр, – ди ансамбль җитәкчесе Лариса Гайнетдинова.

Педагоглар – Альбина Миңнемөхәммәтова, Сергей Тепин, Ландыш Габделфәртова, Рәзилә Мөбарәкова, Ләйсирә Йосыпова «Асылъяр» ансамблендә шөгыльләнүче балаларны системалаштырылган гомуми программа буенча укыталар. Әлеге программа җыр (халык, эстрада җырлары), бию (халык, классик биюләр), музыка





кораллары (традицион), декоратив-гамәли иҗат (чигү, туку, сәйлән үрү һәм башкалар), татар теле һәм музыка грамотасын (сольфеджио, музыка дөньясы) үз эченә ала.

«Асылъяр» үрнәк ансамбле – Гран-при иясе һәм күп кенә Халыкара, Бөтенроссия, республика конкурслары лауреаты, Татарстан Республикасы Бөтендөнья татар конгрессы Гранты гоноранты, һәм шулай ук Татарстан Республикасы Рәисе Рөстәм Миңнехановтан татар милли киемнәре тегү өчен бирелгән сертификат иясе. Бүгенге көндә «Асылъяр» ансамбле Удмуртия Республикасы татарларының региональ милли-мәдәни автономиясе, Удмуртия татар иҗтимагый үзәге ярдәме белән уңышлы эшләп килә, традицион бәйрәмнәр, конференцияләр, съездларда актив катнаша, аларда үз регионы территориясендә һәм аннан читтә яшәүче татар халкының бай мәдәниятын тәкъдим итә.

Фоторәсемнәр Лариса Гайнетдинованың шәхси архивыннан

# КЫШКЫ АЛАНДА

Наилә Яхина көе һәм сүзләре




*Карларны тигезләп иркен аланда,*
*Чыршыны бизәрбез матур яланда.*
*Чакырыйк аюны, керпене табып,*
*Уйнарбыз бергәләп сикереп, чабып.*

***Кушымта:***
*Әгәр син чыксаң*
*Уеннан арып,*
*Утырып ял ит тә*
*Тагын кит чабып.*
*Лә-лә-лә-лә-лә,*
*Лә-лә-лә, лә-лә-лә!*

*Куркыныч түгел лә аю барында,*
*Тәгәрәп ауныйбыз урман карында.*
*Ишетеп тавышны килер Кыш бабай,*
*Иң түргә утырыр Яңа ел – малай.*

***Кушымта:***
*Әгәр син чыксаң*
*Уеннан арып,*
*Утырып ял ит тә*
*Тагын кит чабып.*
*Лә-лә-лә-лә-лә,*
*Лә-лә-лә, лә-лә-лә!*

***«Татарханә» – «Татар киеме», «Татар табыны», «Татар ярышы» рубрикаларында татар халкының этномәдәни мирасын тәкъдим итүче тарихи-агарту проекты. 2022 елда «Татар табыны» рубрикасы татар халкының бөек улы, мәгърифәтче, тел галиме, язучы, тарихчы, этнограф Габделкаюм Габделнасыйр углы Насыйриның махсус хезмәте – «Иршад әл-Әтбиха илә Истихзар әл-Әтгыймә» (1893) («Пешекчегә аш-су әзерләү турында юллама») китабына багышланды. Бирелә ризык әзерләүнең 70 төрле ысулы бәян ителә. Бүген без сезгә шул китаптан бер өзек тәкъдим итәбез.***

КАЮМ НАСЫЙРИ

## ИРШАД ӘЛ-ӘТБИХА

Мәгълүмдер ки, асыл тәгам* ике төрледер. Асыл тәгам бар, тагын мослих** тәгам бар, ягъни асыл тәгам дигәнемез – ашның зарур матдәләредер ки: ит, су, он, ярма, дөге кебек нәрсәләрдер. Мослих тәгам дигәнемез тәгамгә ләззәт бирүче вә һазым*** бирүче – хуш исле кылучы, мөлаем кылучы әйберләр. Мәсәлән, тоз, суган, борыч, лимон, серкә, керән кебек нәрсәләрдер. Тозны гарәпләр Әбу Мослих тәсмия кылмышлардыр, ягъни ашны ислах кылучы матдәләрнең иң зарур булганы – тоздыр. Ләкин кирәкле чамада булырга тиештер, әмма бу ризыкны яхшылатучы матдәләр могтәдил**** микъдарда булмаса, ихтимал, зарары булмак. Янә тәгам хәзерләмәкнең иң олуг гамәле табигыйдыр, ягъни пешмәк вә пешермәк дигән гамәлләрдер ки. Пешмәк вә пешермәкнең төрләре күптер, чөнки тәгам яки су белән пешерәләрдер, дәхи дә шурпада, яки корылай таба кебек нәрсәдә кәбаб кылынадыр. Кайсы булса да шартлары бардыр: вә могтәдил микъдарда пешмәк тиештер, чөнки тәгам артык пешеп китсә дә ләззәте җуеладыр – чи булса да, яки пешәр-пешмәс булса да яхшы булмыйдыр. Шурпада пешкән ит бик яхшы, ләкин тәнгә тукландыра торганы шурпадыр. Кәбаб тукландыручы ризыкларның яхшырагыдыр вә файдалырагыдыр, ләкин ашказаны зәгыйфь кемсәнәгә күп ашарга ярамыйдыр. Булса да аз микъдарда булмак тиеш вә һәм бәгъзе вакытта гына бик сирәк кулланырга кирәк.

## ҖИРЕНӘ ВӘ ВАКЫТЫНА КАРАП ТӘГАМ

Мәгълүмдер ки, тәне вә табигате таза кеше яшелчә һәм иттән булган ризыкны, һәркайсысын да ашыйдыр. Аның каршында һәркайсы бәрабәрдер, ләкин эссе тарафларда тәгам өчен яшелчә яхшырактыр, салкын якларда итле ризык. Безнең ошбу җиремез уртача тарафтан буладыр, шуңа күрә яшелчә белән итле ризык катыш кулланырга яраклыдыр.

## РИЗЫКНЫҢ ЧАМАСЫ

Билгеле ки, адәм угланнары ашарга бик тә комсызлардыр, хәтта ихтыяҗ кадәреннән һәм артык ашыйлар. Шул җәһәттән ашаган тәгамнәре тәмам үзләштерелеп җитмидер, артык күп ашап яшәүче кеше сәламәт тәнле була алмас, киресенчә, зәгыйфь вә кыска гомерлерәк булыр. Бер адәмгә бер ашарга бер кадак ризык җитәрлектер. Әгәр берәү үзенең гадәтенчә ашап күбрәк су эчсә, аш сеңдерүе зәгыйфьләнер. Бәс, аның зәгыйфьләнгәнен сизсә, бер көн, ике көн ашамый тору тиештер.

## АШАУНЫҢ ВАКЫТЫ

Ризык ашаучы кешегә авызына алган ризыкны озак чәйнәргә кирәк, җиңел үзләштерелсен өчен. Чөнки озак чәйнәү белән тәгамгә төкерек күп катышадыр ки, ягъни ашаганда ризыкка никадәр төкерек катышса, шулкадәр сеңдерелүе җиңел буладыр. Әгәр ризык берничә төрле табактан бирелә торган булса, 3-5 минут ашарга кирәк, күп булса, бер сәгать кирәк.

## АШАГАНДА УКУДАН ТУКТАП ТОРУ

Ягъни инфигалать нәфсания вакытында билкөллия ашаудан манигъланмак юлыдыр, чөнки ашаган вакытта гакыл рәхәт булсын вә зиһен һичнәрсә белән мәшгуль булмасын. Хәтта ашаган вакытта кайгы вә көенеч вә хафачылык китерә торган сүзләрне билкөллия сөйләшмәскә тиеш, чөнки күңел хуш вакытта тәгам сәһелрәк һизым кылынадыр. Кайгы вә хәсрәт һизымга манигъдыр.

**(«Татарханә» проектының презентация материаллары җыентыгы: ТАТАРХАНӘ / ТАТАРХАНЕ / TATARHANE. – Казан, 2022)**

---
* Тәгам – ашамлык, ризык.
** Мослих – яхшылатучы.
*** Һазым – аш сеңдерү, аш үтү.
**** Могтәдил – уртача.




«Татарханә» проектының «Татар табыны» рубрикасыннан. Мастер-классны «Тәмле булсын» рестораннар челтәре җитәкчесе, Татар ашлары һәм мәдәнияте Халыкара ассоциациясе президенты, Татарстан Республикасының атказанган халыкка хезмәт күрсәтү өлкәсе хезмәткәре, танылган аш-су остасы **Резидә Кыям кызы ХӨСӘЕНОВА** алып бара

# КҮРКӘ *кәбабы*

Ошбу кәбаб гаять татлы тәгамдер. Кәбаб кылынмыш күркәне дөге белән янә кәбаб кыл ошбу ысулча.

**КИРӘКЛЕ ИНГРЕДИЕНТЛАР:**

*250 грамм дөге;*
*800 миллилитр сөт;*
*2 данә йомырка;*
*100 грамм акмай;*
*800 грамм күркә ите;*
*тәменчә тоз, борыч.*



**1** 250 грамм дөгене сөткә салып ботка пешерәбез. Пешеп чыккан боткага ике йомырка сытабыз.



**2** Күркә итен юып, юка итеп телемләп бүләбез.



**3** Ит телемнәре эченә берәр аш кашыгы ботка салабыз.



**4** Тутырылган итләрне төреп, тишекләрен каплап, табага тезәбез.



**5** Өсләрен эретелгән акмай белән майлыйбыз, тәменчә тоз, борыч сибеп, 200 градуска кадәр җылытылган духовкада 40 минут пешерәбез.



**6** Әзер кәбабны өстәлгә кискәләп, янына яшелчәләр турап чыгарабыз.

*Ашларыгыз тәмле булсын!*

Фоторәсемнәр Татарстан Республикасының мәдәният өлкәсендә инновацияләр һәм традицияләр саклау ресурс үзәге архивыннан

# *Бергәләп бизибез!*



# Истәлекле даталар
2025

## ГЫЙНВАР

**4 гыйнвар**

Опера җырчысы, ТАССРның атказанган артисты Камил Нургали улы Якуповның тууына 100 ел (1925-2006)

**5 гыйнвар**

Рәссам, Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе Әнвәр Гыйләҗетдин улы Сәгыйтовка 90 яшь (1935)

**10 гыйнвар**

Татарстанның халык язучысы, ТАССРның, РСФСРның атказанган сәнгать эшлеклесе, Татарстанның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Нәкый Сираҗетдин улы Исәнбәтнең (Закировның) тууына 125 ел (1900 /иске стиль 29.12.1899-1992)

**13 гыйнвар**

Опера җырчысы, ТАССРның атказанган артисты Йосыф Гыйззәтуллинның тууына 100 ел (1925-2005)

**18 гыйнвар**

Мәдәният эшлеклесе, Татарстан ССРның, Россия Федерациясенең, Кырым Автономияле Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре Илдус Габдрахман улы Тархановка 75 яшь (1950)

**19 гыйнвар**

Җырчы, СССРның халык артисты Азат Зиннәт улы Аббасовның тууына 100 ел (1925-2006)

**22 гыйнвар**

Рәссам-график, Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре Лилия Сәгадәт кызы Золондиновага 70 яшь (1955)

**25 гыйнвар**

Рәссам, Татарстанның Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе, Россия Федерациясенең атказанган рәссамы Александр Сергеевич Федотовка 70 яшь (1955)

**30 гыйнвар**

Җырчы, Г. Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясенең сәнгать җитәкчесе, фольклор музыкасының Дәүләт ансабле җитәкчесе, Татарстан Республикасының халык, Россия Федерациясенең атказанган артисты Айдар Фәтхрахман улы Фәйзрахмановка 70 яшь (1955)

## ФЕВРАЛЬ

**13 февраль**

Балет артисты һәм педагог, ТАССРның халык артисты Сания Хәсән кызы Хантимеровага 80 яшь (1945)

**14 февраль**

Күренекле мәгърифәтче-галим, тарихчы, этнограф, тел белгече, әдип Каюм Насыйриның (Габделкаюм Габденнасыйр улы Насыйровның) тууына 200 ел (1825-1902)

**15 февраль**

Җырчы, ТАССРның һәм РСФСРның халык артисты, Татарстанның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Илһам Гыйльметдин улы Шакировның тууына 90 ел (1935-2019)

**25 февраль**

Композитор, Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе, М. Җәлил исемендәге Республика премиясе лауреаты Риф Хөббулла улы Гатауллинга 75 яшь (1950)

## МАРТ

**1 март**

Рәссам, график, каллиграф Мәхмүт Хөсәен улы Исмәгыйлевкә 75 яшь (1950)

**3 марта**

Актриса, Татарстан Республикасының халык артисты, Россия Федерациясенең атказанган артисты Рузия Һидиятулла кызы Мотыйгуллинага 75 яшь (1950)

**9 март**

Актёр, режиссёр Гали Әхсән улы Ильясовның тууына 125 ел (1900-1970)

**15 март**

Театр эшлеклесе, 1985-2012 елларда Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры директоры булган, Татарстан Республикасының һәм Россия Федерациясенең атказанган мәдәният хезмәткәре Шамил Зиннур улы Закировның тууына 80 ел (1945-2012)

**18 март**

Баянчы Мөхтәр Хисаметдин улы Әхмәдиевнең тууына 100 ел (1925-1987)

**24 март**

Җырчы, ТАССРның атказанган артисты Галия Шәриф кызы Гафиятуллинаның тууына 110 ел (1915-2003)

**24 март**

Җырчы, педагог, Татарстан Республикасының һәм Россия Федерациясенең халык артисты, Татарстанның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Венера Әхәт кызы Ганиевага 70 яшь (1955)

**30 март**

Опера артисты, Россия Федерациясенең атказанган, Татарстан Республикасының халык артисты, Татарстанның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе һәм Россиянең «Алтын битлек» илкүләм театраль-фестивале лауреаты Әхмәт Илтифат улы Агадига 60 яшь (1965)

**https://kitaphane.tatarstan.ru сайтыннан алынды**





**Кадерле укучыларыбыз!**
2025 елның беренче яртыеллыгы өчен «Түгәрәк уен» альманахына республикабызның барлык элемтә бүлекләрендә, яисә «Почта России» сайты аша (https://podpiska.pochta.ru Индекс ПА 183 яисә «Тугарак уен» дип җыярга) онлайн да язылырга мөмкин.

**Индексыбыз – ПА 183**
**Өч айга язылу бәясе – 294 сум 07 тиен**
**Ярты елга язылу бәясе – 588 сум 14 тиен**

БЕРГӘ БУЛЫЙК, ДУСЛАР!